МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

____18.01.2019_____ Казан ш. №_____23_______

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланган кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

**Боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 19 мартындагы 135 номерлы, 2015 елның 28 июлендәге 346 номерлы, 2016 елның 2 июнендәге 177 номерлы, 2016 елның 6 декабрендәге 385 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына, аны кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.Д.Шәмсиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.С.Габделганиев**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2019 елның 18 гыйнварындагы 23 номерлы боерыгы редакциясендә)

## Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты

### 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ АТАЛЫШЫ

1.1. Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты (алга таба - Регламент) кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашырганда (алга таба - лицензия контроле) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба - Министрлык) гамәлгә ашырган административ процедураларның, административ гамәлләрнең вакытларын, эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясенең аталышы: кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру (алга таба - дәүләт функциясе).

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮЧЕ

1.2. Дәүләт функциясен үтәүче булып Министрлык тора.

Дәүләт функциясен турыдан-туры үтәүче булып Министрлыкның Административ реформа мәсьәләләре буенча идарәсенең лицензияләү бүлеге (алга таба – Бүлек) тора.

Дәүләт функциясе Татарстан Республикасы икътисад министры (алга таба – министр), Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) тарафыннан имзаланган тикшерү үткәрүгә боерык нигезендә вәкаләт бирелгән Министрлыкның вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан үтәлә.

Дәүләт фнукциясен үтәү Министрлык тарафыннан түбәндәгеләр белән хезмәттәшлектә гамәлгә ашырыла:

– планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрүне килештерү, планлы тикшерүләр үткәрү планнарын килештерү турында мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы прокуратура органнары белән (алга таба - прокуратура органнары);

– мөрәҗәгатьләре нигезендә, дәүләт хакимияте органнары, юридик затлар, шәхси эшкуарлар, гражданнар белән;

– шәхси эшкуарлар булмаган, кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсендә техник экспертиза үткәрү буенча махсус белемнәргә, тәҗрибәгә ия булган, контроль буенча чараларны үткәрүгә җәлеп итү максатыннан билгеләнгән тәртиптә Министрлык тарафыннан аттестацияләнгән эксперт - гражданнар белән;

– илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аккредитацияләнгән һәм контроль чараларын үткәрүгә Министрлык тарафыннан җәлеп ителә торган эксперт оешмалар – юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән.

«Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры) тиешле мәгълүмат кертүне билгеләнгән тәртиптә Министрлык вәкаләт биргән вазыйфаи зат башкара.

«Татарстан Республикасының чаралар күрү актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүмат кертүне билгеләнгән тәртиптә Министрлык вәкаләт биргән вазыйфаи зат башкара.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕ ҖАЙГА САЛУЧЫ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.3. Дәүләт функциясе түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006 № 19, ст. 2060, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, ст. 6249, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 99-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 19, ст. 2716, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый территорияләр турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 1, ст. 26, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 11 маендагы 369 номерлы карары белән расланган Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре (алга таба – Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, № 21, ст. 2083, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 11 маендагы 370 номерлы карары белән расланган Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре (алга таба – Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, № 21, ст. 2084, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, ст. 3706, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лицензиянең типлаштырылган формасын раслау турында» 2011 елның 6 октябрендәге 826 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 826 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 42, ст. 5924);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кара һәм төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү турында» 2012 елның 12 декабрендәге 1287 номерлы карары белән расланган Кара һәм төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә (алга таба – Лицензияләү турында нигезләмә ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 51, ст. 7222);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль чараларын үткәрүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырырга вәкаләтле органнар, муниципаль контроль органнары тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү турында» 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 636 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 29, ст. 4142, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, ст. 2825, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алгарышлы социаль-икътисадый территорияләр резидентларына карата дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырырга вәкаләтле органнар, муниципаль контроль органнары үткәрә торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары

(алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 44, ст. 6127);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яки) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга соратулар җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында кисәтү әзерләү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 8, 1239 ст);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шул документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан соратыла һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба - РФ Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Федераль салым хезмәтенең «Юридик затларны, шәхси эшкуарларны һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларын дәүләт теркәвенә алганда теркәү органына тапшырыла торган документларның формаларын һәм рәсмиләштерелүенә карата таләпләрне раслау турында» 2012 елның 25 гыйнварындагы ММВ-7-6/25@ номерлы боерыгы (алга таба – Россия ФСХнең 2012 елның 25 гыйнварындагы ММВ-7-6/25@ номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2012 елның 14 маенда теркәлгән, теркәү номеры 24139, «Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене», 29 октябрь, 2012 ел, №44, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, төзелгән алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар

тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба –Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет порталы, 2017, 21 март);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 елның 19 ноябрендәге 812 номерлы карары белән расланган Физик затлардан кабул итү рөхсәт ителгән төсле металл ватыгы һәм калдыклары исемлеге (алга таба – ТР МК 812 номерлы карары белән расланган исемлек) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары, республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2008, № 14, ст. 0528, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик затлардан кабул итү тыелган, көнкүрешкә карамаган кара металл ватыгы һәм калдыклары исемлеген раслау турында» 2003 елның 11 сентябрендәге 486 номерлы карары (алга таба – ТР МК 486 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары, республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2003, № 19, ст. 59);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары (алга таба – ТР МК 325 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары, республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 30, ст.1057);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы чаралар күрү актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 елның 23 августындагы 593 номерлы карары (алга таба ТР МК 593 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары, республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 65, ст. 2059, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Дәүләт лицензия контроле өлкәсендә техник экспертиза үткәрү буенча экспертларны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 24 декабрендәге 488 номерлы боерыгы (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 2015, 27 гыйнвар).

## ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕ ОБЪЕКТЛАРЫ

1.4. Лицензия контроле объектлары булып кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга лицензия алырга дәгъва кылган яисә лицензиягә ия, шул исәптән алгарышлы социаль-икътисадый территория резидентлары булган, юридик затлар яки шәхси эшкуарлар эшчәнлеге тора (алга таба – лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар).

## ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕ ПРЕДМЕТЫ

1.5. Лицензия контроле предметы булып лицензиягә дәгъва кылучылар һәм лицензиатлар тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрнең үтәлеше тора.

## ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА МИНИСТРЛЫК ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ЧИКЛӘҮЛӘР

1.6. Министрлыкның тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлары лицензия контролен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р боерыгы нигезендә расланган исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түләүсез нигездә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә соратып алырга, шул исәптән электрон рәвештә;

2) тиешле белешмәләрне тикшерүгә лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар тарафыннан мәҗбүри таләпләр үтәлү фактын билгеләүнең таләп ителүе сәбәп булганда һәм күрсәтелгән белешмәләрне бирү федераль законнарда каралган очракта, салым һәм закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил иткән документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратырга;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат тапшырырга, аларны ачарга, шул исәптән законнарда каралган очракларда алар белән танышырга, дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырырга;

4) лицензиягә дәгъва кылучылардан, лицензиатлардан лицензия контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм Россия Федерациясе законнарында тапшырылуы каралган белешмәләрне һәм документларны тиешле тәртиптә соратып алырга;

5) лицензиягә дәгъва кылучыларга һәм лицензиатларга тикшерү үткәрергә;

6) тикшерү барышында ачыкланган лицензия таләпләренең бозылуын бетерү турында лицензиатларга күрсәтмәләр бирергә;

7) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы 5-7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында күрсәтмәләр бирергә;

8) ачыкланган хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә вәкаләтле органнарга мәгълүмат җибәрергә.

1.7. Министрлыкның тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлары лицензия контролен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә бурычлы:

1) Россия Федерациясе законнары нигезендә лицензия контроле өлкәсендә, шул исәптән лицензия таләпләрен бозуны кисәтү, ачыклау һәм чик кую буенча бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә;

2) Россия Федерациясе законнарын, тикшерү үткәрелә торган лицензиягә дәъва кылучыларның һәм лицензиатларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

3) тикшерүне, аның билгеләнүе нигезендә, аны үткәрү турында министр, министр урынбасары боерыгы нигезендә үткәрергә;

4) тикшерүне бары тик хезмәт бурычларын үтәгәндә, күчмә тикшерүне бары тик хезмәт таныклыкларын, тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен һәм, 99-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 10 өлешенең 2 пунктында каралган очракта, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында документ күчермәсен күрсәтеп үткәрергә;

5) тикшерү үткәрелгәндә лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә анда булуына каршы килмәскә һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

6) тикшерү үткәрелгәндә булган лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына карый торган мәгълүмат һәм документларны бирергә;

7) лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;

9) ачыкланган хокук бозулар фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә, күрсәтелгән чараларның хокук бозуларның авырлыгына туры килү-килмәвен, аларның кешеләрнең тормышы, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр), Россия Федерациясе Музей фондының музей предметлары һәм музей коллекцияләре, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документлары, илкүләм китапханә фонды составына керүче махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган документлар өчен, дәүләтнең иминлеге өчен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү өчен потенциаль куркынычлыгын исәпкә алырга, шулай ук гражданнар, шул исәптән шәхси эшкуарлар, юридик затлар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең нигезсез чикләнүенә юл куймаска;

10) лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдергән очракта, үз гамәлләренең нигезле булуын дәлилләргә;

11) тикшерү үткәрүнең 294-ФЗ номерлы Федераль законда һәм 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында билгеләнгән срокларын сакларга;

12) лицензиягә дәгъва кылучылардан, лицензиатлардан Россия Федерациясе законнарында тапшырылуы каралмаган документларны һәм башка мәгълүматларны таләп итмәскә;

13) күчмә тикшерү үткәрелү алдыннан лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле үтенече белән, тикшерү үткәрү өчен нигез булган әлеге Регламентның нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) тикшерүләрнең исәбен алып бару журналында, әгәр лицензиягә дәгъва кылучыда, лицензиатта ул булса (исәп алып бару журналының типлаштырылган формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган), үткәрелгән кучмә тикшерү турында язма кертергә;

1.8. Министрлыкның тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларының лицензия контролен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокукы юк:

1) әгәр мәҗбүри таләпләр әлеге вазыйфаи затлар эш йөртә торган Министрлык вәкаләтләренә карамаса, аларның үтәлешен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән, шулай ук куллану зарурлыгы Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә басылып чыкмаган хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

4) тикшерү кешеләрнең тормышы, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр), Россия Федерациясе Музей фондының музей предметлары һәм музей коллекцияләре, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документлары, илкүләм китапханә фонды составына керүче махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган документлар өчен, дәүләтнең иминлеге өчен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү өчен потенциаль куркыныч тудыру сәбәпле үткәрелгән очрактан тыш, планнан тыш тикшерүне аны үткәргәндә лицензиягә дәгъва кылучыны лицензиатның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмаган очракта үткәрергә;

5) әгәр документлар, мәгълүмат, продукция үрнәкләре тикшерү объектлары яки тикшерү предметлары булмаса яки тикшерү предметына карамаса, аларны тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен тартып алырга;

6) продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү мохите объектларын тикшерү пробаларын аларны тикшерү, сынау, үлчәүне күрсәтелгән үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу турында билгеләнгән формада беркетмәләр рәсмиләштермичә һәм илкүләм стандартларда, үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу кагыйдәләрендә һәм аларны тикшерү, сынау, үлчәү алымнарында, техник регламентларда яки алар үз көченә кергәнче гамәлдә булган башка норматив техник документларда һәм тикшеренүләр, сынаулар, исәпләүләр кагыйдәләрендә һәм алымнарында билгеләнгән нормалардан артык күләмдә алырга;

7) Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил иткән мәгълүматны таратырга;

8) тикшерү үткәрүгә билгеләнгән срокларны арттырырга;

9) лицензиягә дәгъва кылучыларга, лицензиатларга тикшереп тору буенча чараларны алар хисабыннан үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирүне башкарырга;

10) лицензиягә дәгъва кылучыдан, лицензиаттан башка дәүләт органнарында,

җирле үзидарә органнарында яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмаларда булган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документлар һәм (яки) мәгълүмат, шул исәптән рөхсәт бирә торган документлар тапшыруны таләп итәргә;

11) лицензиягә дәгъва кылучыдан, лицензиаттан тикшерү үткәрелә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүмат тапшыруны таләп итәргә. Министрлык тикшерү үткәрү турында боерык кабул иткәннән соң ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүмат соратып алырга хокуклы.

## ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЛИЦЕНЗИЯГӘ ДӘГЪВА КЫЛУЧЫНЫҢ, ЛИЦЕНЗИАТНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.9. Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәрелгәндә, анда турыдан-туры булырга, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) Министрлыктан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына караган һәм бирелүе 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган мәгълүматны алырга;

3) тиешле документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Министрлык тарафыннан алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яки) мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышып чыгуы турында, алар белән, шулай ук Министрлык вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүен яки килешмәвен күрсәтергә;

6) тикшерү үткәргәндә лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның хокукларын бозуга китергән Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законы нигезендә административ тәртиптә һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә;

1.10. Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләргә бурычлы:

1) Министрлыкның лицензия контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларына белешмәләр һәм документлар, шулай ук тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелүе каралган телдән һәм язма аңлатмалар бирергә;

2) тикшерүләр үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларның территориягә, эшчәнлекне гамәлгә ашырганда лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан

файдаланыла торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, урыннарга, лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан кулланыла торган җиһазлар, охшаш объектлар, транспорт чаралары янына үтеп керә алуын тәэмин итәргә;

3) үзе катнашырга яки мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чаралар оештыруга һәм үткәрүгә җаваплы затларның катнашуын тәэмин итәргә.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1.11. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча, 2 нөсхәдә төзелгән кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә Россия Федерациясе законнарындагы лицензия таләпләренең лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан үтәлешен тикшерү акты (алга таба - тикшерү акты);

2) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;

ТР МК 593 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы чаралар күрү актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;

4) тикшерүләрнең исәбен алып бару журналында, әгәр лицензиягә дәгъва кылучыда, лицензиатта ул булса (исәп алып бару журналының типлаштырылган формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган), үткәрелгән күчмә тикшерү турында кертелгән язма;

лицензия таләпләренең бозылуы ачыкланган очракта:

5) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасында күздә тотылган таләпләрдән чыгып, рәсмиләштерелгән лицензия таләпләрен бозулар ачыкланган очракта, ачыкланган лицензия таләпләрен бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә, ачыкланган лицензия таләпләрн бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә), аларны үтәү срокларын күрсәтеп (әлеге Регламентка № 1 кушымта);

кергән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда әзерләнә торган таләп бозулар яки лицензия таләпләрен бозу билгеләре турында мәгълүмат булганда:

6) лицензия таләпләрен бозарга ярамаганлыгы турында кисәтү;

кирәк булган очракта:

лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турында Министрлык боерыгы;

лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында Министрлык боерыгы;

лицензияне гамәлдән чыгару турында арбитраж судка гариза;

7) ачыкланган таләп бозуларны бетерүне тикшереп тору, аларны кисәтү, кешеләрнең тормышы, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр), Россия Федерациясе Музей фондының музей предметлары һәм музей коллекцияләре, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документлары, илкүләм китапханә фонды составына керүче махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган документлар өчен, дәүләтнең

иминлеге өчен зыян килүне, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне будырмый калу буенча чаралар, шулай ук ачыкланган бозуларның барлыкка килүенә юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү.

Дәүләт функциясен башкару өчен нигез гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан Министрлыкка кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат булса (алга таба – мөрәҗәгать итүче), мөрәҗәгать итүчегә дәүләт функциясен башкару нәтиҗәләре буенча җавап 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

Әгәр контроль чарасы барышында контроль чарасы үткәрү объекты булып торган лицензиатның эшчәнлеге законнар таләпләрен бозу белән бәйле булуы билгеле булып, аларны ачыклау, кисәтү һәм булдырмый калу мәсьәләләре Министрлык компетенциясенә карамаган очракта, Министрлык мондый хокук бозулар турында мәгълүматны (белешмәләрне) Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органнарына җибәрергә бурычлы.

## 2. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Министрлыкның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан ш., Мәскәү ур., 55нче й.

2.2. Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00дан алып 18.00гә кадәр, җомга 9.00дан алып 16.45кә кадәр, төшке аш 12.00дән алып 12.45кә кадәр.

2.3. Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча Министрлыкка документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен адреслар һәм телефоннар:

Министрлыкның почта адресы:

420021, Татарстан Республикасы, Казан ш., Мәскәү ур., 55нче й.

Министрлык Бүлегенең белешмәләр өчен телефоннары: 524-91-48, 524-91-49, 524-90-22;

Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mert.tatarstan.ru;

электрон почта адресы: mineconom@tatar.ru.

2.4. Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча, Министрлыкның урнашу урыны һәм эш графиклары турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

1) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән телефоннар аша);

2) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән түбәндәге электрон почта аша электрон документ рәвешендә: mineconom@tatar.ru);

3) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://mert.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

4) лицензия контроле турында мәгълүматны үз эченә алган һәм Министрлык бинасы эчендә урнашкан мәгълүмат стендлары аша;

2.5. «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтына, Министрлык бинасындагы мәгълүмат стендына Бүлек белгече түбәндәге мәгълүматны урнаштыра һәм аны яңартып тора:

- Россия Федерациясе законнарының һәм Татарстан Республикасы законнарының дәүләт функциясен үтәү тәртибенә кагылышлы төп нигезләмәләре турында;

Министрлык ел саен расланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү программасы;

- үтәлеш бәясе лицензия контроле предметы булган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яки аларның аерым өлешләре исемлеге, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстлары;

- лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар өчен лицензия таләпләренең үтәлеше мәсьәләләре буенча бастырылган белешмәлекләр турында, шул исәптән лицензия таләпләрен үтәү, семинарлар һәм конференцияләр үткәрү, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлатмалар бирү аша һәм башка ысуллар белән урнаштырылган мәгълүмат турында белешмәләр;

- лицензия таләпләре исемлеге, ә лицензия таләпләре үзгәргән очракта, мәҗбүри таләпләр билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларның гамәлгә керү сроклары һәм тәртибе турында шәрехләүләр, шулай ук мәҗбүри таләпләр кертүне һәм аларның үтәлешен тәэмин итүне күздә тоткан кирәкле оештыру чаралары, техник чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр;

- елына кимендә бер тапкыр башкарыла торган лицензия контролен гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү, шул исәптән лицензия таләпләре бозылуның иң еш очрый торган очракларын күрсәтеп, һәм мондый бозуларга юл куймау максатларында лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар тарафыннан күрелергә тиешле чараларга кагылышлы тәкъдимнәр биреп;

- әлеге Регламент;

- Министрлык боерыгы белән расланган план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – План);

- Министрлыкның урнашу урыны, эш графигы, телефоннары һәм факс номерлары, Министрлыкның электрон адресы;

- дәүләт функциясен үтәү барышында башкарылган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга шикаять бирү тәртибе;

- дәүләт функциясен үтәгәндә гамәлләр эзлеклелеген күрсәтә торган блок-схема.

2.6. Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать иткәннән соң кичекмәстән бирелә, язма мөрәҗәгатькә һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгатькә җавап әлеге

мөрәҗәгать Министрлыкта теркәлгән көннән алып, календарь көннәрендә исәпләнә торган утыз көнлек срокта, 59-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, күрсәтелгән почта адресына яки электрон адреска юллана.

Министрлыкта шалтыратуны кабул иткән вазыйфаи затның куелган сорауларга җавап бирү мөмкинлеге булмаса, телефон шалтыратуы бүтән вазыйфаи затка адреслана (күчерелә) яки мөрәҗәгать итүчегә кирәкле мәгълүматны алып булган телефон номеры хәбәр ителә.

## КОНТРОЛЬ ЧАРАЛАРЫН ҮТКӘРГӘН ӨЧЕН ЛИЦЕНЗИЯГӘ ДӘГЪВА КЫЛУЧЫЛАРДАН, ЛИЦЕНЗИАТЛАРДАН ТҮЛӘҮ АЛУНЫҢ РӨХСӘТ ИТЕЛМӘВЕ

2.7. Лицензияләргә дәгъва кылучылардан, лицензиатлардан контроль чаралары үткәрүгә, шул исәптән, тикшерүләр үткәрүгә җәлеп ителгән очракта, экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәте күрсәтүгә түләү алынмый.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ СРОГЫ

2.8. Тикшерүләрнең һәркайсын (планлы, планнан тыш, күчмә һәм документларга) үткәрү срогы егерме эш көненнән артык була алмый.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен елына илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

Алгарышлы социаль-икътисадый территориянең бер резидентына планлы тикшерү срогы аны үткәрә башлау датасыннан алып унбиш эш көненнән артмый.

Алгарышлы социаль-икътисадый территориянең кече эшкуарлык субъекты булган бер резидентына планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен елына кырык сәгатьтән һәм микропредприятие өчен ун сәгатьтән артык була алмый. Министрлыкның план буенча күчмә тикшерүләр үткәрә торган вазыйфаи затларының сәбәпләре аңлатылган тәкъдимнәренә нигезләнгән катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү зарур булган аерым очракларда тикшерү үткәрү срогы озайтыла, әмма кече предприятиеләр өчен ун эш көненнән, микропредприятиеләр өчен ун сәгатьтән күбрәккә түгел.

Алгарышлы социаль-икътисадый территориянең бер резидентына карата планнан тыш тикшерү срогы биш эш көненнән арта алмый.

2.9. Министрлыкның план буенча күчмә тикшерүләр үткәрә торган вазыйфаи затларының сәбәпләре аңлатылган тәкъдимнәренә нигезләнгән катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү зарур булган аерым очракларда план буенча күчмә тикшерү үткәрү срогы министр тарафыннан озайтыла ала, әмма егерме эш көненнән, кече предприятиеләр өчен илле сәгатьтән, микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән күбрәккә түгел.

2.10. Кече эшкуарлык субъектына карата планлы күчмә тикшерү үткәрү, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу таләп ителгән очракта, тикшерү үткәрүне министр (министр

урынбасары) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле срокка, әмма иң күбе ун эш көненә, туктатып тора ала. Тикшерү үткәрүне кабат туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, урыннарында, башка объектларында күрсәтелгән тикшерү белән бәйле Министрлык гамәлләре туктатылып тора.

2.11. Үз эшчәнлеген Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә гамәлгә ашыра торган лицензиатка карата тикшерүләрнең һәркайсын (документларга да, күчмә дә) үткәрү срогы юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе буенча аерым билгеләнә, бу вакытта тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы алтмыш эш көненнән артык була алмый.

2.12. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

## ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР

2.13. Планлы тикшерүләр Министрлык тарафыннан эшләнә һәм раслана торган план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – План) нигезендә үткәрелә. Министр тарафыннан расланган План «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

Алгарышлы социаль-икътисадый территория резидентларына карата тикшерүләрнең еллык планы Министрлык тарафыннан эшләнә һәм, 473-ФЗ номерлы Федераль закон, 1132 номерлы РФ Хөкүмәте карары нигезендә, вәкаләтле федераль органга килештерүгә һәм 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, прокуратура органнарына килештерүгә юллана.

2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорда «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы нигезләмәләренә ярашлы рәвештә кече эшкуарлык субъектларына караган, алар турында мәгълүматлар кече эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.2 статьясы таләпләренә туры китереп оештырыла һәм үткәрелә.

2.14. Лицензиатларга карата планлы тикшерүләр түбәндәгечә үткәрелә:

1) лицензия бирү турында карар кабул иткән көннән алып бер елдан да иртәрәк түгел;

2) соңгы планлы тикшерү үткәрү көненнән алып өч елдан да иртәрәк түгел.

2.15. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләр:

1) лицензия таләпләренең ачыкланган бозылуын бетерү турында элек Министрлык тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең лицензиат тарафыннан үтәлү срогы бетү, бу очракта тикшерү предметы Министрлык тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше генә була ала;

2) Министрлыкка лицензия таләпләренең лицензиат тарафыннан тупас бозылу фактлары турында гражданнардан, шул исәптән юридик затлардан, шәхси

эшкуарлардан гаризалар керү, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат алыну;

3) 99-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләре нигезендә лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору срогы үтү;

4) Министрлык күрсәтмәсен вакытыннан алда үтәү фактын билгеләү максатларында Министрлык тарафыннан планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында лицензиат үтенече булу;

5) Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре буенча чыгарылган Министрлык боерыгы булу;

6) лицензиягә дәгъва кылучы тарафыннан лицензия бирү турында яки лицензиат тарафыннан лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза бирелү (99-ФЗ номерлы Федеарль законның 13 һәм 18 статьяларында каралган очракларда, лицензия бирүче орган документларга тикшерүне һәм планнан тыш күчмә тикшерүләрне билгеләнгән тәртипитә прокуратура органнары белән килештермичә үткәрә).

2.16. Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда лицензия таләпләрен тупас бозуларның тулы исемлеге Лицензияләү турында нигезләмәдә билгеләнә. Бу очракта лицензия таләпләрен мондый бозуларга түбәндәгеләргә китергән бозулар керергә мөмкин:

а) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкарьләргә) зыян килү, шулай ук техноген характердагы гадәттән тыш хәл булу куркынычы янау;

б) кеше корбаннары яки гражданнар сәламәтлегенә зур зыян килү, ике һәм аннан күбрәк гражданның сәламәтлегенә уртача авырлыктагы зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкарьләргә) зыян килү, техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү, гражданнарның хокукларына, законлы мәнфәгатьләренә, ил оборонасына һәм дәүләт иминлегенә зыян салыну.

2.17. Министрлыкка мөрәҗәгать итүченең шәхесен ачыкларга мөмкинлек бирмәүче мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгатьтә яки гаризада күрсәтелгән мәгълүмат әлеге Регламентның 2.15 пунктыдагы 2 пунктча нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып торса, планнан тыш тикшерү Министрлыкка мөрәҗәгать итүченең шәхесен ачыклау мөмкинлеге булган очракта гына үткәрелә ала. Мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карала.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә юлланган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен алар мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мәҗбүри авторизациясен күздә тоткан мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре чараларын кулланып җибәрелгән шартта гына нигез була ала.

2.18. Әлеге Регламентның 2.5 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны карап

тикшергәндә элек кергән охшаш мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре, шулай ук тиешле лицензиатларга карата элек үткәрелгән контроль чаралары нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.19. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүмат бирелмәгән булса, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары кергән мәгълүматка алдан тикшерү үткәрергә мөмкин. Кергән мәгълүматка алдан тикшерү үткәрү барышында гаризалар һәм мөрәҗәгать юллаган, мәгълүмат биргән затлар турында өстәмә белешмәләр һәм материаллар сорату (шул исәптән телдән) буенча чаралар күрелә, лицензиатның Министрлык карамагында булган документлары карала, кирәк очракта, лицензиат белән хезмәттәшлектән тыш һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат бирү һәм Министрлык таләпләрен үтәү буенча бурычларны йөкләүдән тыш, контроль чаралары уздырыла. Алдан тикшерү кысаларында лицензиаттан әлеге алынган мәгълүматка кагылышлы аңлатмалар бирүе соралырга мөмкин, әмма мондый аңлатмалар бирү һәм башка документлар тапшыру мәҗбүри түгел.

2.20. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуына юл куйган затлар билгеле булганда, әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүмат алынса, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү билгеләү турында сәбәпләре күрсәтелгән күрсәтмә әзерли. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча лицензиатны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

2.21. Алдан тикшерү, планнан тыш тикшерү, әгәр тиешле тикшерү башланганнан соң аның оештырылуына сәбәп булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән белешмәләрнең күрәләтә дөрес булмавы билгеләнсә, министр (министр урынбасары) карары белән туктатыла.

2.22. Әгәр гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә күрәләтә дөрес булмаган белешмәләр күрсәтелгән булса, Министрлык гражданнан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшкуардан күрсәтелгән затларның гаризаларын, мөрәҗәгатьләрен карау белән бәйле Министрлык чыгымнарын түләттерү турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.23. Лицензиатка әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерү, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән билгеләнгән тәртиптә килештерелгәннән соң, лицензиатка алдан хәбәрнамә җибәрмичә генә үткәрелергә мөмкин.

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне Министрлыкның прокуратура органы белән килештерүе турында гаризаның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

## ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕН ҮТКӘРҮНЕ ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР

2.24. Министрлыкның лицензия контролен үткәрүче вазыйфаи затлары:
- министр;
- министр урынбасары (лицензия контроле өлкәсе өчен җаваплы);
- Бүлек башлыгы;
- Бүлекнең әйдәп баручы киңәшчеләре;
- Бүлекнең әйдәп баручы консультантлары.

Лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча тикшерүне түбәндәгеләр турыдан-туры үткәрә ала:
- Бүлек башлыгы;
- Бүлекнең әйдәп баручы киңәшчеләре;
- Бүлекнең әйдәп баручы консультантлары.

## ЛИЦЕНЗИЯГӘ ДӘГЪВА КЫЛУЧЫЛАРНЫҢ, ЛИЦЕНЗИАТЛАРНЫҢ 294-ФЗ НОМЕРЛЫ ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННЫ, 99-ФЗ НОМЕРЛЫ ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННЫ БОЗГАН ӨЧЕН ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.25. 294-ФЗ номерлы Федераль законның бозылуына юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез каршылык күрсәтүче, тикшерүләр үткәрүдән качучы һәм (яки) мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуларын бетерү турында Министрлык күрсәтмәсенең билгеләнгән срогын үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, юридик затларның башка вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

## ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРГӘН ВАКЫТТА МИНИСТРЛЫКНЫҢ, АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.26. Министрлык, аның вазыйфаи затлары функцияләрен, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, тикшерү үткәргәндә хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәлләр кылмаган) очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында Министрлык хокуклары һәм (яки) мәнфәгатьләре бозылган лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка мондый чаралар күрелгән көннән алып ун көн эчендә язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 3. ЛИЦЕНЗИЯГӘ ДӘГЪВА КЫЛУЧЫГА, ЛИЦЕНЗИАТКА КАРАТА КУЕЛА ТОРГАН ЛИЦЕНЗИЯ ТАЛӘПЛӘРЕ

3.1. Лицензия контролен үткәргәндә лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка карата куела торган лицензия таләпләренең, тикшерү үткәргәндә лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка карата куела торган лицензия таләпләрен билгели торган норматив хокукый актларның исемлеге 1нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица – Лицензия контролен үткәргәндә лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка карата куела торган мәҗбүри таләпләрнең һәм аларны билгели торган норматив хокукый актларның исемлеге

| **Контрольдә тотыла торган объектлар** | **Мәҗбүри таләпнең билгеләнеше** | **Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив хокукый акт** | **Тикшерү үткәргәндә лицензияләргә дәгъва кылучылар, лицензиатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге** |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **Төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату** | | | |
| 1.1. Лицензияләргә дәгъва кылучылар һәм лицензиатлар (эшләр төре – төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату) | 1) лицензиягә дәгъва кылучының һәм лицензиатның лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыруның һәрбер урынында лицензияләнә торган кирәкле таләпләргә туры килердәй, милек хокукында яки закон нигезендә башкача рәвештә җир кишәрлекләренең, биналарының, төзелмәләренең, корылмаларының, бүлмәләренең, техник чаралар, җиһазларының һәм техник документларының булуы | 99-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасы, Лицензияләү турында нигезләмәнең 5 пунктындагы «а» пунктчасы | Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аңа милек хокукында яки башка законлы нигездә караган, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында алар буенча хокуклары теркәлмәгән җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр (биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләрнең аерымланган бердәм өлеше) булуын раслый торган документларның күчермәләре (әгәр мондый хокуклар күрсәтелгән реестрда теркәлгән булса, әлеге җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр турында белешмәләр бирелә);<br>лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аның милке булган яки башка законлы нигездә аңа караган лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | кулланыла торган техник чаралары, җиһазлары һәм техник документациясе булуны раслый торган документларның күчермәләре |
| | 2) лицензиягә дәгъва кылучының һәм лицензиатның алар белән хезмәт шартнамәләре төзегән, һөнәри белемнәре булган, лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле тиешле квалификациягә һәм (яки) эш стажына ия хезмәткәрләре булу | 99-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 пунктындагы 2 пунктчасы | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре таләпләре нигезендә лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) белән хезмәт шартнамәләре төзегән хезмәткәрләрнең квалификациясен раслый торган документларның күчермәләре;<br>ватыкка һәм калдыкларга радиация контролен, ватык һәм калдыкларның шартлау куркынычсызлыгына контроль үткәрү өчен Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре таләпләре нигезендә лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) җитәкчесе тарафыннан расланган җаваплы затларны билгеләү турындагы документларның күчермәләре; |
| | 3) лицензиягә дәгъва кылучының «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законның 13.1 статьясы нигезендә, Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре таләпләрен үтәү өчен шартларга ия булуы һәм лицензиат тарафыннан Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләрен үтәү | Лицензияләү турында нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасы | |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| | **Төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итүне оештыруга карата таләпләр** | | |
| | 1) төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү буенча һәр объектта күренеп торган урында түбәндәге мәгълүматларның булуы: | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пункты | |
| | а) юридик зат атамасы яки шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аларның телефон номерлары | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пунктындагы «а» пунктчасы | Мәгълүматның булу-булмавы күчмә тикшерү вакытында объектта тикшерелә |
| | б) юридик затлар өчен – төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү өчен җаваплы зат турында мәгълүматлар | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пунктындагы «б» пунктчасы | Мәгълүматның булу-булмавы күчмә тикшерү вакытында объектта тикшерелә |
| | в) эш тәртибе | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пунктындагы «в» пунктчасы | Мәгълүматның булу-булмавы күчмә тикшерү вакытында объектта тикшерелә |
| | г) төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү шартлары һәм бәяләре | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пунктындагы «г» пунктчасы | Мәгълүматның булу-булмавы күчмә тикшерү вакытында объектта тикшерелә |
| | д) ТР МК 812 номерлы карары белән расланган физик затлардан кабул итеп алуга рөхсәт ителгән төсле металл ватыгы һәм калдыклары исемлеге | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 | ТР МК 812 номерлы карары белән расланган физик затлардан кабул итеп алуга рөхсәт ителгән төсле металл ватыгы һәм калдыклары |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| | | пунктындагы «д» пунктчасы | исемлеге |
| | 2) төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү объектларында түбәндәге документларның булуы | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пункты | |
| | а) Лицензияләү турында нигезләмәгә туры китереп алынган лицензия яки лицензияне биргән лицензияләүче орган раслаган күчермәсе (лицензиатлар өчен генә) | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «а» пунктчасы | Лицензияләү турында нигезләмәгә туры китереп алынган лицензия яки лицензияне биргән лицензияләүче орган раслаган күчермәсе (лицензиатлар өчен генә) |
| | б) юридик зат турында - Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына, шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына язма кертелү фактын раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «б» пунктчасы | Юридик зат турында - Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына, шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына язма кертелү фактын раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе |
| | в) булган җиһазларга һәм җайланмаларга документлар, шулай ук аларны тикшерү һәм сынау турында документлар | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «в» пунктчасы | Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аның милке булган яки башка законлы нигездә аңа караган лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган техник чаралары, җиһазлары һәм техник документациясе булуны раслый торган документларның күчермәләре |
| | г) төсле металл ватыгына һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү, аларны шартлау куркынычсызлыгына тикшерү тәртибе турында кулланмалар | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 | Төсле металл ватыгына һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү, аларны шартлау куркынычсызлыгына тикшерү |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | пунктындагы «г» пунктчасы | тәртибе турында кулланмалар |
| | д) төсле металлның радиоактив ватыгы һәм калдыклары табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «д» пунктчасы | Төсле металлның радиоактив ватыгы һәм калдыклары табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма |
| | е) шартлау куркынычы булган предметлар табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пунктындагы «е» пунктчасы | Шартлау куркынычы булган предметлар табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма |
| | **Төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү, исәпкә кую һәм саклау тәртибенә карата таләпләр** | | |
| | 1) лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш: | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 9 пункты (1) | |
| | а) тиешле квалификациясе булган, хезмәт шартнамәләре төзелгән түбәндәге хезмәткәрләрнең минималь штаты булу:<br>2 разрядлы металл ватыгы һәм калдыклары контролеры – төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү буенча һәр объектта;<br>1 разрядлы металл ватыгын һәм калдыкларын пресслаучы– Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү объектларының кимендә берсендә; | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 9 пунктындагы (1) «а» пунктчасы | Лицензиягә дәгъва кылучылар (лицензиатлар) белән хезмәт шартнамәләре төзегән хезмәткәрләрнең квалификациясен раслый торган документларның күчермәләре |
| | 2) төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итә | Төсле металл ватыгы һәм | Ватыкка һәм калдыкларга радиация |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| | торган һәр объектта түбәндәгеләрнең булуы:<br>төсле метал ватыгы һәм калдыкларының радиация контролен үткәрү өчен җаваплы зат<br>төсле метал ватыгы һәм калдыкларының шартлау куркынычсызлыгы контролен үткәрү өчен җаваплы зат | калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 9 (1) пунктындагы «б» пунктчасы | контролен һәм ватык белән калдыкларны шартлау куркынычсызлыгына тикшерүне үткәрү өчен җаваплы затларны билгеләү турында документларның лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) җитәкчесе тарафыннан расланган күчермәләре |
| | в) төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү буенча һәр объектта төсле металл ватыгын һәм калдыкларын саклау өчен билгеләнгән каты (асфальт, бетон) өслекле мәйданчык, шулай ук төсле металл ватыгына һәм калдыкларына билгеләнгән таләпләр нигезендә радиация контролен үткәрү өчен җиһаз булу | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 9 (1) пунктындагы «в» пунктчасы | Төсле металл ватыгына һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү өчен лицензиягә дәгъва кылучыда (лицензиатта) аның милке булган һәм аңа башка законлы нигездә караган җиһазның һәм техник документациянең булуын раслый торган документларның күчермәләре |
| | г) Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү объектларының кимендә берсендә түбәндәгеләрнең булуы:<br>төсле металл ватыгы һәм калдыкларының химик составын билгеләү җиһазы<br>төсле металл ватыгын һәм калдыкларын пакетлау прессы | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 9 (1) пунктындагы «г» пунктчасы | Төсле металл ватыгының һәм калдыкларының химик составын билгеләү өчен лицензиягә дәгъва кылучыда аның милке булган һәм аңа башка законлы нигездә караган җиһазның, төсле металл ломын һәм калдыкларын пакетлау прессы булуын раслый торган документларның күчермәләре һәм техник документация |
| | 2) төсле металл ватыгын кабул итү ватык тапшыручы затның шәхесен таныклый торган документ күрсәтелгәндә аның язма гаризасына нигезләнеп башкарыла | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 7 пункты | Ватык тапшыручы затларның гаризасы |
| | 3) төсле металл ватыгын һәм калдыкларын 14 яшенә җитмәгән затлардан кабул итү тыела. Төсле металл ватыгын 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге затлардан | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу | Ватык тапшыручы затларның гаризалары арасында 14 яшенә җитмәгән затлар гаризаларының |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | кабул итү аларның законлы вәкилләренең – ата-аналарының, уллыкка алучыларның яки попечительләренең язма ризалыгы белән рөхсәт ителә, моңа 16 яшькә җиткән һәм билгеләнгән тәртиптә тулысынча юридик хокукка ия дип танылган затлар керми | кагыйдәләренең 8 пункты | булмавы;<br>14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге затлар өчен – аларның законлы вәкилләренең язма ризалыгы |
| | 4) төсле металл ватыгын кабул итү ватыкның һәр партиясенә мәҗбүри рәвештә кабул итү-тапшыру актын төзеп башкарыла | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 11 пункты | Кабул итү-тапшыру актлары |
| | 5) кабул итү-тапшыру актлары кабул итү-тапшыру актларын исәпкә кую кенәгәсендә теркәлә | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 12 пункты | Кабул итү-тапшыру актларын исәпкә кую кенәгәсе |
| | 6) төсле металлның көнкүреш (физик затлардан кабул итеп алынган) һәм сәнәгать ватыгын саклау аерым-аерым башкарыла | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 19 пункты | Күчмә тикшерү вакытында |
| | **Тартып алына торган төсле металл ватыгының һәм калдыкларының исәбен алып бару тәртибе** | | |
| | тартып алынган төсле металл ватыгының һәм калдыкларының һәр партиясе төяп җибәрелгән төсле металл ватыгын һәм калдыкларын теркәү журналында теркәлә | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 21 пункты | Төяп җибәрелгән төсле металл ватыгын һәм калдыкларын теркәү журналы |
| **Кара металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату** | | | |
| 1.2. Лицензияләргә дәгъва кылучылар һәм | 1) лицензиягә дәгъва кылучының һәм лицензиатның лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыруның һәрбер урынында лицензияләнә торган кирәкле таләпләргә туры килердәй, милек хокукында яки закон | 99-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 пунктындагы 1 пунктчасы | Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аңа милек хокукында яки башка законлы нигездә караган, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| лицензиатлар (эшләр төре – кара металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату) | нигезендә башкача рәвештә җир кишәрлекләренең, биналарының, төзелмәләренең, корылмаларының, бүлмәләренең, техник чаралар, җиһазларының һәм техник документларының булуы | Лицензияләү турында нигезләмәнең 5 пунктындагы «а» пунктчасы | реестрында алар буенча хокуклары теркәлмәгән җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр (биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләрнең аерымланган бердәм өлеше) булуын раслый торган документларның күчермәләре (әгәр мондый хокуклар күрсәтелгән реестрда теркәлгән булса, әлеге җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр турында белешмәләр бирелә);<br>лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аның милке булган яки башка законлы нигездә аңа караган лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган техник чаралары, җиһазлары һәм техник документациясе булуны раслый торган документларның күчермәләре |
| | 2) лицензиягә дәгъва кылучының һәм лицензиатның алар белән хезмәт шартнамәләре төзегән, һөнәри белемнәре булган, лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле тиешле квалификациягә һәм (яки) эш стажына ия хезмәткәрләре булу | 99-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 пунктындагы 2 пунктчасы | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре таләпләре нигезендә лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) белән хезмәт шартнамәләре төзегән хезмәткәрләрнең квалификациясен раслый торган документларның күчермәләре;<br>ватыкка һәм калдыкларга радиация контролен, ватык һәм калдыкларның шартлау куркынычсызлыгына |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | контроль үткәрү өчен Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре таләпләре нигезендә лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) җитәкчесе тарафыннан расланган җаваплы затларны билгеләү турындагы документларның күчермәләре; |
| | 3) лицензиягә дәгъва кылучының «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законның 13.1 статьясы нигезендә, Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре таләпләрен үтәү өчен шартларга ия булуы һәм лицензиат тарафыннан Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләрен үтәү | Лицензияләү турында нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасы | |
| | **Кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итүне оештыруга карата таләпләр** | | |
| | 1) кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү буенча һәр объектта күренеп торган урында түбәндәге мәгълүматларның булуы: | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пункты | |
| | а) юридик зат атамасы яки шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аларның телефон номерлары | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пунктындагы «а» пунктчасы | Мәгълүматның булу-булмавы күчмә тикшерү вакытында объектта тикшерелә |
| | б) юридик затлар өчен – кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү өчен җаваплы зат турында мәгълүматлар | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пунктындагы «б» | Мәгълүматның булу-булмавы күчмә тикшерү вакытында объектта тикшерелә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | пунктчасы | |
| | в) эш тәртибе | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пунктындагы «в» пунктчасы | Мәгълүматның булу-булмавы күчмә тикшерү вакытында объектта тикшерелә |
| | г) кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү шартлары һәм бәяләре | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 4 пунктындагы «г» пунктчасы | Мәгълүматның булу-булмавы күчмә тикшерү вакытында объектта тикшерелә |
| | 2) кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү объект-ларында түбәндәге документ-ларның булуы | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пункты | |
| | а) Лицензияләү турында нигезләмәгә туры китереп алынган лицензия яки лицензияне биргән лицензияләүче орган раслаган күчермәсе (лицензиатлар өчен генә) | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «а» пунктчасы | Лицензияләү турында нигезләмәгә туры китереп алынган лицензия яки лицензияне биргән лицензияләүче орган раслаган күчермәсе (лицензиатлар өчен генә) |
| | б) юридик зат турында - Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына, шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына язма кертелү фактын раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «б» пунктчасы | Юридик зат турында - Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына, шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына язма кертелү фактын раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | в) булган җиһазларга һәм җайланмаларга документлар, шулай ук аларны тикшерү һәм сынау турында документлар | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «в» пунктчасы | Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аның милке булган яки башка законлы нигездә аңа караган лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган техник чаралары, җиһазлары һәм техник документациясе булуны раслый торган документларның күчермәләре |
| | г) кара металл ватыгына һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү, аларны шартлау куркынычсызлыгына тикшерү тәртибе турында кулланмалар | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «г» пунктчасы | Кара металл ватыгына һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү, аларны шартлау куркынычсызлыгына тикшерү тәртибе турында кулланмалар |
| | д) кара металлның радиоактив ватыгы һәм калдыклары табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «д» пунктчасы | Кара металлның радиоактив ватыгы һәм калдыклары табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма |
| | е) шартлау куркынычы булган предметлар табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 5 пунктындагы «е» пунктчасы | Шартлау куркынычы булган предметлар табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма |
| | **Кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү, исәпкә кую һәм саклау тәртибенә карата таләпләр** | | |
| | 1) лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш: | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 8 (1) | |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | пункты | |
| | а) тиешле квалификациясе булган, хезмәт шартнамәләре төзелгән түбәндәге хезмәткәрләрнең минималь штаты булу:<br>2 разрядлы металл ватыгы һәм калдыклары контролеры – кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү буенча һәр объектта;<br>1 разрядлы металл ватыгын һәм калдыкларын пресслаучы– Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү объектларының кимендә берсендә; | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 8 (1) «а» пунктчасы | Лицензиягә дәгъва кылучылар (лицензиатлар) белән хезмәт шартнамәләре төзегән хезмәткәрләрнең квалификациясен раслый торган документларның күчермәләре |
| | б) кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итә торган һәр объектта түбәндәгеләрнең булуы:<br>кара металл ватыгы һәм калдыкларының радиация контролен үткәрү өчен җаваплы зат<br>кара металл ватыгы һәм калдыкларының шартлау куркынычсызлыгы контролен үткәрү өчен җаваплы зат | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 8 (1) пунктындагы «б» пунктчасы | Ватыкка һәм калдыкларга радиация контролен һәм ватык белән калдыкларны шартлау куркынычсызлыгына тикшерүне үткәрү өчен җаваплы затларны билгеләү турында документларның лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) җитәкчесе тарафыннан расланган күчермәләре |
| | в) кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү буенча һәр объектта кара металл ватыгын һәм калдыкларын саклау өчен билгеләнгән каты (асфальт, бетон) өслекле мәйданчык, шулай ук кара металл ватыгына һәм калдыкларына билгеләнгән таләпләр нигезендә радиация контролен үткәрү өчен җиһаз булу | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 8 (1) «в» пунктчасы | Кара металл ватыгына һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү өчен лицензиягә дәгъва кылучыда (лицензиатта) аның милке булган һәм аңа башка законлы нигездә караган җиһазның һәм техник документациянең булуын раслый торган документларның күчермәләре |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | г) Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү объектларының кимендә берсендә түбәндәгеләрнең булуы:<br>кара металл ватыгын пакетлау өчен пресс (пресслау көче 2500 кН.на ким булмаган), яисә пресс-кайчы (кисү көче 3000 кН.нан ким булмаган), яисә җиңел үлчәмдәге ватыкны ваклау һәм сортларга аеру өчен җиһаз (привод куәте 495 кВт.тан ким булмаган)<br>йомычканы сортларга аеру һәм ваклау җиһазы | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 8 (1) пунктындагы «г» пунктчасы | Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аның милке булган яки башка законлы нигездә аңа караган кара металл ватыгын пакетлау өчен прессы (пресслау көче 2500 кН.на ким булмаган), яисә пресс-кайчысы (кисү көче 3000 кН.нан ким булмаган), яисә җиңел үлчәмдәге ватыкны ваклау һәм сортларга аеру өчен җиһазы (привод куәте 495 кВт.тан ким булмаган), йомычканы сортларга аеру һәм ваклау җиһазы булуны раслый торган документлар күчермәләре |
| | 2) кара металл ватыгын кабул итү ватыкның һәр партиясенә мәҗбүри рәвештә кабул итү-тапшыру актын төзеп башкарыла | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 10 пункты | Кабул итү-тапшыру актлары |
| | 3) кабул итү-тапшыру актлары кабул итү-тапшыру актларын исәпкә кую кенәгәсендә теркәлә | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 11 пункты | Кабул итү-тапшыру актларын исәпкә кую кенәгәсе |
| | **Тартып алына торган кара металл ватыгының һәм калдыкларының исәбен алып бару тәртибе** | | |
| | тартып алынган кара металл ватыгының һәм калдыкларының һәр партиясе төяп җибәрелгән кара металл ватыгын һәм калдыкларын теркәү журналында теркәлә | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләренең 18 пункты | Төяп җибәрелгән кара металл ватыгын һәм калдыкларын теркәү журналы |

3.2. Лицензиатлар тарафыннан лицензия таләпләрен бозуны кисәтү, лицензия таләпләрен бозуга этәрүче сәбәпләр, факторлар һәм шартларны бетерү максатларында, Министрлык, таләп бозуларны кисәтү буенча ел саен үзе раслый торган программа нигезендә, лицензия таләпләрен бозуны кисәтү буенча чаралар башкара.

3.3. Министрлыкта кергән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыклары расланмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалардан тыш), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматта лицензия таләпләрен бозуга әзерләнү яки бозу билгеләре турында белешмәләр булса, әгәр лицензия таләпләрен бозуның кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкарьләргә), Россия Федерациясе Музей фондының музей предметлары һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, илкүләм китапханә фонды составына керүче махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган документларга, дәүләтнең иминлегенә зыян салуы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүгә китерүе яки күрсәтелгән нәтиҗәләрнең янавын булдыруы турында раслаучы мәгълүматлар юк икән, Министрлык юридик затка, шәхси эшкуарга лицензия таләпләрен бозарга ярамаганлыгы турында кисәтү игълан итә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга лицензия таләпләре үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм мондый кисәтүдә билгеләнгән срокта бу хакта хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Лицензия таләпләрен бозарга ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм юллау, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата ризасызлыклар белдерү һәм Министрлыкның аларны карап тикшерүе, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүне үтәү турында Министрлыкка хәбәр итү тәртибе 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ ЛИЦЕНЗИЯГӘ ДӘГЪВА КЫЛУЧЫЛАР, ЛИЦЕНЗИАТЛАР КҮРСӘТӘ ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар тарафыннан күрсәтелә торган документлар, шулай ук мондый документларның формаларын раслый торган норматив хокукый актлар исемлеге 2нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица – Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар тарафыннан күрсәтелә торган документлар

| **Тикшерү үткәргәндә лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар тарафыннан тапшырыла торган** | **Документ формасын билгели торган норматив** |
|---|---|

| документлар исемлеге | хокукый акт |
|---|---|
| **Төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату** | |
| 1. Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аңа милек хокукында яки башка законлы нигездә караган, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында алар буенча хокуклары теркәлмәгән җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр (биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләрнең аерымланган бердәм өлеше) булуын раслый торган документларның күчермәләре (әгәр мондый хокуклар күрсәтелгән реестрда теркәлгән булса, әлеге җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр турында белешмәләр бирелә);<br>лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аның милке булган яки башка законлы нигездә аңа караган лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган техник чаралары, җиһазлары һәм техник документациясе булуны раслый торган документларның күчермәләре | РФ Гражданлык кодексы<br>(1 өлеш, 2 өлеш, 3 өлеш)<br>РФ Җир кодексы |
| 2. Төсле металл ватыгы белән эш итү кагыйдәләре таләпләре нигезендә лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) белән хезмәт шартнамәләре төзегән хезмәткәрләрнең квалификациясен раслый торган документларның күчермәләре;<br>ватыкка һәм калдыкларга радиация контролен, ватык һәм калдыкларның шартлау куркынычсызлыгына контроль үткәрү өчен Төсле металл ватыгы белән эш итү кагыйдәләре таләпләре нигезендә лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) җитәкчесе тарафыннан расланган җаваплы затларны билгеләү турындагы документларның күчермәләре; | РФ Хезмәт кодексы |
| 3) Төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү буенча һәр объектта күренеп торган урында түбәндәге мәгълүматларның булуы:<br>а) юридик зат атамасы яки шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аларның телефон номерлары;<br>б) юридик затлар өчен – төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү өчен җаваплы зат турында мәгълүматлар;<br>в) эш тәртибе;<br>г) төсле металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү шартлары һәм бәяләре;<br>д) ТР МК 812 номерлы карары белән расланган физик затлардан кабул итеп алуга рөхсәт ителгән төсле металл ватыгы һәм калдыклары исемлеге | - |
| 4) Лицензияләү турында нигезләмәгә туры китереп алынган лицензия яки лицензияне биргән лицензияләүче орган раслаган күчермәсе (лицензиатлар өчен генә) | РФ Хөкүмәтенең 826 номерлы карары |
| 5. Юридик зат турында - Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына, шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына язма кертелү фактын раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе | Россия ФСХ 25.01.2012 ел ММВ-7-6/25@ номерлы боерыгы |

| | |
|---|---|
| 6. Булган җиһазларга һәм җайланмаларга документлар, шулай ук аларны тикшерү һәм сынау турында документлар | - |
| 7. Төсле металл ватыгына һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү, аларны шартлау куркынычсызлыгына тикшерү тәртибе турында кулланмалар | - |
| 8. Төсле металлның радиоактив ватыгы һәм калдыклары табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма | - |
| 9. Шартлау куркынычы булган предметлар табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма | - |
| 10. Ватык тапшыручы затның гаризасы | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре |
| 11. Кабул итү-тапшыру актлары | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре |
| 12. Кабул итү-тапшыру актларын исәпкә кую кенәгәсе | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре |
| 13. Төяп җибәрелгән төсле металл ватыгын һәм калдыкларын теркәү журналы | Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре |
| **Кара металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату** | |
| 1. Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аңа милек хокукында яки башка законлы нигездә караган, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында алар буенча хокуклары теркәлмәгән җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр (биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләрнең аерымланган бердәм өлеше) булуын раслый торган документларның күчермәләре (әгәр мондый хокуклар күрсәтелгән реестрда теркәлгән булса, әлеге җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр турында белешмәләр бирелә);<br>лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) аның милке булган яки башка законлы нигездә аңа караган лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган техник чаралары, җиһазлары һәм техник документациясе булуны раслый торган документларның күчермәләре | РФ Гражданлык кодексы (1 өлеш, 2 өлеш, 3 өлеш)<br>РФ Җир кодексы |
| 2. Кара металл ватыгы белән эш итү кагыйдәләре таләпләре нигезендә лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) белән хезмәт шартнамәләре төзегән хезмәткәрләрнең квалификациясен раслый торган документларның күчермәләре;<br>ватыкка һәм калдыкларга радиация контролен, ватык һәм калдыкларның шартлау куркынычсызлыгына контроль үткәрү өчен Кара металл ватыгы белән эш итү кагыйдәләре таләпләре нигезендә лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) җитәкчесе тарафыннан расланган җаваплы | РФ Хезмәт кодексы |

| | |
|---|---|
| затларны билгеләү турындагы документларның күчермәләре; | |
| 3. Кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү буенча һәр объектта күренеп торган урында түбәндәге мәгълүматларның булуы:<br>а) юридик зат атамасы яки шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аларның телефон номерлары;<br>б) юридик затлар өчен – кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү өчен җаваплы зат турында мәгълүматлар;<br>в) эш тәртибе;<br>г) кара металл ватыгын һәм калдыкларын кабул итү шартлары һәм бәяләре | - |
| 4) Лицензияләү турында нигезләмәгә туры китереп алынган лицензия яки лицензияне биргән лицензияләүче орган раслаган күчермәсе (лицензиатлар өчен генә) | РФ Хөкүмәтенең 826 номерлы карары |
| 5. Юридик зат турында - Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына, шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына язма кертелү фактын раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе | Россия ФСХ 25.01.2012 ел ММВ-7-6/25@ номерлы боерыгы |
| 6. Булган җиһазларга һәм җайланмаларга документлар, шулай ук аларны тикшерү һәм сынау турында документлар | - |
| 7. Кара металл ватыгына һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү, аларны шартлау куркынычсызлыгына тикшерү тәртибе турында кулланмалар | - |
| 8. Кара металлның радиоактив ватыгы һәм калдыклары табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма | - |
| 9. Шартлау куркынычы булган предметлар табылганда гамәлләр тәртибе турында кулланма | - |
| 10. Кабул итү-тапшыру актлары | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре |
| 11. Кабул итү-тапшыру актларын исәпкә кую кенәгәсе | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре |
| 12. Төяп җибәрелгән кара металл ватыгын һәм калдыкларын теркәү журналы | Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны тартып алу кагыйдәләре |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ, АЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

5.1. Дәүләт фнукциясен үтәү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

тикшерүләр үткәрүне планлаштыру;

планлы күчмә тикшеү үткәрү;

документларга планнан тыш тикшерү үткәрү;

планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү;

ачыкланган лицензия таләпләрен бозуларны бетерү буенча чаралар күрү.

Планлы тикшерү күчмә тикшерү рәвешендә үткәрелә. Планнан тыш тикшерү документларга тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү рәвешендә үткәрелә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата лицензия контроле әлеге Регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында, РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

5.2. Лицензия контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру блок-схемасы әлеге Регламентка 2нче кушымтада китерелгән.

## «ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮНЕ ПЛАНЛАШТЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.3. Административ процедураны башлау өчен еллык Тикшерүләр планын әзерләү срогы җитү нигез булып тора.

5.4. План Бүлек тарафыннан 294-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары нигезендә эшләнә.

5.5. Планлы тикшерүләр лицензиатларга карата үткәрелә. Лицензиатка планлы тикшерүне еллык Планга кертү өчен нигез булып әлеге Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.6. Бүлек башлыгы План әзерләү буенча җаваплы вазыйфаи затны (вазыйфаи затларны) (алга таба – План әзерләү буенча җаваплы башкаручы) билгели.

Башкару срогы: планлы тикшерүләр үткәрү елы алдыннан булган елның 1 июленә кадәр.

5.7. План әзерләү буенча җаваплы башкаручы:

1) РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары нигезендә билгеләнгән форма буенча План проектын төзи;

2) аны министр, министр урынбасары белән килештерә;

башкару срогы: планлы тикшерүләр үткәрү елы алдыннан булган елның 20 августына кадәр;

3) План проектын, карап тикшерү өчен, планлы тикшерүләр үткәрү планлаштырылган юридик затларның, шәхси эшкуарларның урнашу урыны буенча кәгазь чыганакта (электрон рәвештә күчермәсен кушып), тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта юллавы аша яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, прокуратура органына җибәрә.

башкару срогы: планлы тикшерүләр үткәрү елы алдыннан булган елның 1

сентябренә кадәр.

5.8. Прокуратура органы План проектын карап тикшергәннән соң һәм тәкъдимнәр керткәннән соң, План әзерләү өчен җаваплы башкаручы ачыкланган кисәтүләрне бетерә һәм Планны министр раслагач, аны прокуратура органнарына җибәрә.

Башкару срогы: расланган Планны прокуратура органнарына җибәрү - планлы тикшерүләр үткәрү елы алдыннан булган елның 1 ноябренә кадәр.

5.9. План әзерләү өчен җаваплы башкаручы расланган Планны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыруны оештыра.

Башкару срогы: Планның раслану вкытыннан алып 5 эш көне дәвамында.

5.10. РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карарында билгеләнгән очракларда раслаучы документлар булганда, Планга үзгәрешләр кертергә мөмкин.

Планга үзгәрешләр кертү Министрлык боерыгы белән гамәлгә ашырыла. Кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүмат аларны кертү вакытыннан алып 3 эш көне дәвамында кәгазь чыганакта (электрон рәвештә күчермәсен кушып), тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта юллавы аша яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, тиешле прокуратура органына җибәрелә, шулай ук үзгәрешләр кертү вакытыннан алып 5 эш көне дәвамында билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

## «ПЛАНЛЫ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.11. «Планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен тиешле лицензиатны еллык Планга кертү һәм лицензиатка планлы күчмә тикшерү үткәрү сроклары җитү нигез була.

Лицензиатка планлы тикшерүне еллык Планга кертү әлеге Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча гамәлгә ашырыла.

5.12. Лицензиатка планлы тикшерүләр предметы булып лицензиат документларында аның эшчәнлеге, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган бүлмәләр, биналар, корылмалар, техник чаралар, җиһазлар, башка объектларның торышы, лицензиат хезмәткәрләренең лицензия таләпләренә туры килүе турында мәгълүматлар, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр, лицензия таләпләрен үтәү буенча лицензиат күргән чаралар тора.

5.13. Күчмә тикшерү (планлысы да, планнан тыш да) лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның лицензияләнә торган эшчәнлек төрен фактик гамәлгә ашыру урыны буенча уздырыла.

5.14. «Планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы үз эченә түбәндәге административ гамәлләрне ала:

1) тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

2) тикшерү үткәрү турында боерыкны рәсмиләштерү;

3) тикшерү үткәрү турында лицензиатка хәбәр итү;

4) тикшерү үткәрү;

5) тикшерү актын рәсмиләштерү.

5.15. Еллык План нигезендә Бүлек башлыгы лицензиатка планлы күчмә тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затны (вазыйфаи затларны) (алга таба – җаваплы башкаручы) билгели (әлеге Регламентның 2.24 пункты).

Күчмә тикшерү үткәрү вакытында экспертлар, эксперт оешмалары катнашуы таләп ителсә, тикшерү үткәрелә торган лицензиат белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерә торган затларга бәйле затлар булмаган экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре җәлеп ителә.

Башкару срогы: планлы тикшерү үткәрү башланганчы ким дигәндә биш көн алдан.

Гамәл нәтиҗәсе: тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеге.

5.16. Җаваплы башкаручы планлы күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли һәм аны министрга (министр урынбасарына) кул кую өчен җибәрә.

Тикшерү үткәрү турында боерыкның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Тикшерү министр (министр урынбасары) боерыгында күрсәтелгән вазыйфаи зат яки вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелә ала.

Башкару срогы: планлы тикшерү үткәрү башланганчы ким дигәндә дүрт көн алдан.

Гамәл нәтиҗәсе: планлы күчмә тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) кул куйган боерык.

5.17. Җаваплы башкаручы план буенча күчмә тикшерү үткәрелү турында лицензиатка план буенча күчмә тикшерү үткәрелү турында боерыкның күчермәсен тапшырылуы хәбәр ителә торган заказлы почта юлламасы белән һәм (яки) квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы куелган һәм лицензиатның электрон почта адресына, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса яисә лицензиат тарафыннан Министрлыкка элек тапшырылган булса, электрон документ рәвешендә яки мөмкин булган башка ысул белән хәбәр итә.

Башкару срогы: лицензиатка планлы күчмә тикшерү үткәрелә башлаганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итлерегә тиеш.

Гамәл нәтиҗәсе: тикшерү үткәрү турында боерыкның лицензиатка юлланган күчермәсе.

Лицензиат адресына хәбәрнамә юллау Министрлыкта эш башкаруны алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәп куела.

5.18. Тикшерү боерыкта күрсәтелгән вазыйфаи зат яки вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелә ала.

Җаваплы башкаручы күчмә тикшерүне түбәндәге гамәлләрдән башлый:

хезмәт таныклыгын күрсәтүдән;

лицензиатның җитәкчесен яки башка вазыйфаи затын, аның вәкаләтле вәкилен түбәндәгеләр белән мәҗбүри таныштырудан:

күчмә тикшерү билгеләү турында министр (министр урынбасары) боерыгы белән (министр (министр урынбасары) боерыгының мөһер белән расланган күчермәсе лицензиатның җитәкчесенә яки башка вазыйфаи затына, аның вәкаләтле вәкиленә хезмәт таныклыгын күрсәтү белән бер үк вакытта имза куйдырып

тапшырыла);

күчмә тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре белән;

күчмә тикшерү үткәрү максатлары, бурычлары, нигезләре белән;

контроль чаралары төрләре һәм күләмнәре белән;

күчмә тикшерүгә җәлеп ителгән экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре составы белән;

аны үткәрү сроклары һәм шартлары белән.

Тикшерелергә тиешле затларның таләбе буенча Министрлыкның вазыйфаи затлары үзләренең вәкаләтләрен раслау максатларында Министрлык, контроль чаралары үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә тиеш.

5.19. Лицензиатның җитәкчесе яки башка вазыйфаи заты, аның вәкаләтле вәкиле күчмә тикшерү үткәрүче Министрлыкның вазыйфаи затларына күчмә тикшерү максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле документларны, әгәр күчмә тикшерү алдыннан документларга тикшерү уздырылмаса, аларны күрсәтергә, шулай ук күчмә тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларга һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларга, эксперт ошемалары вәкилләренә эшчәнлекне гамәлгә ашырганда юридик зат, шәхси эшкуар куллана торган биналар, төзелмәләр, корылмалар, бүлмәләр территориясенә үтеп керүне, юридик зат, шәхси эшкуар файдалана торган җиһазны, шуңа охшаш объектларны, транспорт чараларын һәм алар ташый торган йөкне карауны тәэмин итәргә бурычлы.

Тикшерү үткәргәндә Министрлыкның вазыйфаи затлары эшчәнлегенә комачаулык тудыру белән бәйле хокук бозулар өчен РФ КоАП 19.4.1 статьясы нигезендә административ җаваплылык каралган.

5.20. Җаваплы башкаручы планлы күчмә тикшерү барышында контроль буенча түбәндәге чараларны үткәрә:

- лицензиат документларында аның эшчәнлеге, файдалана торган бүлмәләр, биналар, корылмалар, техник чаралар, җиһазлар, башка объектлар торышы турында мәгълүматны бәяли;

- лицензиат эшчәнлегенең әлеге Регламентның 3 бүлегендә куелган мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәвен, шул исәптән лицензиат хезмәткәрләренең лицензия таләпләренә туры килүен, башкарыла торган эшләрне, күрсәтелә торган хезмәтләрне, лицензиат тарафыннан лицензия таләпләрен үтәү буенча күрелгән чараларны бәяли;

Башкару срогы: планлы тикшерү үткәрү турында боерыкта күрсәтелгән, әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән вакыттан артмаган срокларда.

Гамәл нәтиҗәсе: үткәрелгән контроль чаралары.

5.21. Тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган формада, 2 нөсхәдә тикшерү актын төзи.

Тикшерү үткәргәндә лицензиат тарафыннан лицензия таләпләренең бозылуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы:

- ачыкланган барлык бозу очракларын тикшерүләр актында теркәп куя;

- лицензиатка ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең срокларын күрсәтеп,тикшерү актына кушымта итеп бирелгән һәм (яки) кешеләр

тормышына, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян килүне булдырмый калу буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар турында күрсәтмә бирә, һәм әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тота;

Тикшерү актына үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизаларның нәтиҗәләре, лицензиатның мәҗбүри таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләре аңлатмалары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле бүтән документлар һәм аларның күчермәләре кушымта итеп бирелә.

Тикшерү акты  тикшерү төгәлләнгәннән соң ук ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аның берсе кушымта күчермәләре белән, тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә аның белән танышып чыгудан баш тарту турында кул куйдыртып, лицензиат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тапшырыла, икенчесе (кушымталары белән бергә) Министрлыкта кала торган лицензия делосына беркетеп куела.

Лицензиатның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук лицензиат тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә аның белән танышып чыгудан баш тарту турында кул куюдан баш тарткан очракта, тикшерү акты тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы почта юлламасы белән җибәрелә, ул Министрлыкта лицензия делосында саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетеп куела.

Тикшерелә торган затның лицензия контроле кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә  ризалыгы булган очракта, тикшерү акты әлеге актны төзегән затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә лицензиатның җитәкчесенә, аның башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Бу очракта тикшерелә торган затка әлеге актны төзегән затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә әлеге документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган дип санала.

Башкару срогы: тикшерү актын тапшыру яки почта юлламасы һәм электрон документ рәвешендә җибәрү - тикшерү тәмамланганнан соң ук.

Гамәл нәтиҗәсе: ике нөсхәдә тикшерү акты, аның берсе лицензиатка тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе лицензия эшенә беркетеп куелган.

5.22. Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмә алу таләп ителә икән, тикшерү акты контроль чаралары төгәлләнгәннән соңгы өч эш көненнән артып китмәгән срокта төзелә һәм, кул куйдыртып, лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тапшырыла яисә тапшырылуы хәбәр ителә торган заказлы почта юлламасы белән һәм (яки) әлеге актны төзегән затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә  (тикшерелә торган затның лицензия контроле кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә  ризалыгы булган очракта), күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелә.  Бу очракта күрсәтелгән документның тапшырылуы турында хәбәрнамә һәм (яки) башкача раслау тикшерү

актының Министрлык делосында саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетеп куела.

5.23. Җаваплы башкаручы тикшерүләрне исәпкә алу журналына (ул булган очракта) үткәрелгән тикшерү турында язма кертә.  Тикшерүләрне исәпкә алу журналының типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Үткәрелгән тикшерү турында язма Министрлык атамасы, тикшерү үткәрүнең башлану һәм төгәлләнү даталары, аны үткәрү вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләрне үз эченә ала, шулай ук тикшерүне үткәрүче затны яки вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, аның яки аларның имзалары күрсәтелә.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы беркетелгән, номер сугылган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның мөһере (мөһер булган очракта) белән расланган булырга тиеш.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаган очракта тикшерү актына тиешле язма кертелә.

Башкару срогы: тикшерү тәмамланганнан соң.

Гамәл нәтиҗәсе: тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән тикшерү турында язма яисә тикшерү актында тиешле язма.

5.24. Тикшерү үткәрелгән лицензиат тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәләр белән килешмәгән очракта, тикшерү актын алу датасыннан башлап унбиш көн эчендә Министрлыкка язма рәвештә тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән тулысынча яки аның аерым нигезләмәләре белән килешмәвен белдерергә хокуклы. Шул ук вакытта лицензиат мондый инкарь итүләргә әлеге инкарь итүләрнең нигезләнгән булуын раслый торган документларны яки аларның таныкланган күчермәләрен кушып бирергә яисә аларны килешенгән срокта Министрлыкка тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы куелган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә  җибәрелергә мөмкин.

5.25. Әгәр планлы күчмә тикшерү үткәрү лицензиат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең урында булмавы аркасында яисә лицензиат эшчәнлегенең чынбарлыкта гамәлгә ашырылмавына, яисә лицензиат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең тикшерү үткәрелүнең мөмкин булмавына китергән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә башкарылмаса, Министрлыкның вазыйфаи заты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи, анда аны үткәрүнең мөмкин булмавы сәбәпләре күрсәтелә.  Бу очракта Министрлык тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзегән көннән алып өч ай эчендә мондый лицензиатларга карата планлы күчмә тикшерүне үткәрү турында карарны планлы  тикшерүләрнең еллык планына кертмичә генә һәм лицензиатка алдан хәбәр итмичә генә кабул итәргә хокуклы.

5.26. «Планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасын башкару нәтиҗәсе тиешле тәртиптә электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтына куела, «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына, Татарстан Республикасының чара күрү актларының җыелма реестрына, тикшерүләрне исәпкә алу журналына кертелә.

## «ДОКУМЕНТЛАРГА ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.27. «Документларына планнан тыш тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез була.

5.28. Лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның документларына тикшерү предметы булып, бирелгән гаризаларда һәм документларда бәян ителгән мәгълүматларның 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләргә һәм 18 статьясындагы 3 өлешкә, шулай ук лицензиягә дәгъва кылучы яки лицензиат турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында һәм башка федераль мәгълүмат ресурсларында булган мәгълүматларга туры килүен бәяләү тора.

Лицензиатның документларына тикшерү предметы булып лицензиат документларында аның эшчәнлеге, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган бүлмәләр, биналар, корылмалар, техник чаралар, җиһазлар, башка объектларның торышы, лицензиат хезмәткәрләренең лицензия таләпләренә туры килүе турында мәгълүматлар, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр, лицензия таләпләрен үтәү, лицензия таләпләрен бозуның ачыкланган очракларын бетерү турында күрсәтмәләрне үтәү буенча лицензиат күргән чаралар тора.

5.29. Документларга планнан тыш тикшерү Министрлыкның урнашу урыны буенча үткәрелә.

5.30. Документларга планнан тыш тикшерү

5.31. Әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек башлыгы, әлеге Регламентның 5.15 пунктына таянып, документларга планнан тыш тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгели.

Башкару срогы: Документларга планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән алып бер эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: документларга планнан тыш тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.32. Җаваплы башкаручы документларга планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли һәм аны министрга (министр урынбасарына) кул кую өчен җибәрә.

Тикшерү үткәрү турында боерыкның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Документларга планнан тыш тикшерү лицензиягә дәгъва кылучының лицензия бирү турындагы гаризасына яки лицензиатның лицензияне яңадан рәсмиләштерү

турындагы гаризасына нигезләнеп үткәрелгән очракта, җаваплы башкаручы алынган документларның 99-ФЗ номерлы Федераль законның тиешенчә 13, 18 статьяларында каралган таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә.

Бу очракта документларга планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерык проекты лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан лицензия бирү яки яңадан рәсмиләштерү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар тулы күләмендә тапшырылган көннән алып өч эш көне эчендә әзерләнә.

Башкару срогы: тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручы билгеләнгән көннән алып ике эш көне эчендә яисә лицензиягә дәгъва кылучы яки лицензиат тарафыннан тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза бирелгән көннән алып өч эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: документларга планнан тыш тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) кул куйган боерык.

5.33. Документларга планнан тыш тикшерү үткәрү процессында җаваплы башкаручы иң беренче чиратта лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның Министрлык карамагында булган документларын, шул исәптән лицензия делоларын, алдагы тикшерүләр актларын һәм әлеге лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка карата гамәлгә ашырылган лицензия контроле нәтиҗәләре турындагы башка документларны карый.

5.34. Җаваплы башкаручы:

белешмәләрнең дөреслеген бәяли;

документларда булган белешмәләрнең лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат эшчәнлегенең билгеләнгән мәҗбүри таләпрләргә туры килүен бәяли;

кирәк булган очракта, белешмәләрне ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек ярдәмендә ала.

Министрлык карамагындагы документларда булган белешмәләрнең дөреслеге нигезләнгән шик тудырса яисә бу белешмәләр лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан лицензия таләпләренең үтәлү-үтәлмәвен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, әгәр хаталар һәм (яки) каршылыклар, тапшырылган документлардагы белешмәләрнең Министрлыкта булган белешмәләргә туры килмәве ачыкланса, җаваплы башкаручы лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат адресына тапшырылуы хәбәр ителә торган заказлы почта юлламасы белән яки мөмкин булган башка ысул белән, документларга планнан тыш тикшерү үткәрү барышында карау өчен кирәкле башка документларны сәбәпләре аңлатылган сорату алган көннән соң ун эш көне эчендә тапшыру таләп итеп, хат (сәбәпләре аңлатылган сорату) юллый.

Хатка (сәбәпләре аңлатылган соратуга) документларга планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерыкның мөһер белән таныкланган күчермәсе кушып бирелә.

Тикшерү үткәрү турында боерык кабул ителгәннән соң, җаваплы башкаручы тикшерү гамәлгә ашырылган лицензиягә дәгъва кылучыдан, лицензиаттан әлеге Регламентның 1 һәм 2нче таблицаларында күрсәтелгән кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратырга хокуклы.

Кирәк булган очракта, җаваплы башкаручы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең әлеге Регламентка 3нче кушымтада күрсәтелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары яки җирле

үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә сората һәм ала, шул исәптән электрон рәвештә.

Җаваплы башкаручы лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштыра.

Башкару срогы: документларга планнан тыш тикшерү үткәрелә башлаган көннән сигез эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: җаваплы башкаручы тарафыннан Министрлык карамагындагы каралган документлар һәм (яки) мәгълүмат; карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбе белән лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат адресына юлланган хат (сәбәпләре аңлатылган сорату); лицензия контроле үткәрү максатлары өчен кирәкле, башка органнардан алынган белешмәләр һәм документлар.

Хат (сәбәпләре аңлатылган сорату) юллау Министрлыкта эш башкаруны алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәп куела.

Министрлыкка тапшырыла торган документлар күчермәләрен, әгәр башкасы Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, нотариаль таныклау таләп ителергә тиеш түгел.

5.35. Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат хатта (сәбәпләре аңлатылган соратуда) күрсәтелгән документларны мөһер белән (булган очракта) һәм тиешенчә лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырырга бурычлы. Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат хатта (сәбәпләре аңлатылган соратуда) күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

Тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга яисә әлеге документлардагы белешмәләрнең Министрлыкта булган документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә кагылышлы Министрлыкка аңлатмалар бирә торган лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат өстәмә рәвештә Министрлыкка элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документлар тапшырырга хокуклы.

Башкару срогы: сәбәпләре аңлатылган сорату алынган көннән ун эш көне дәвамында.

5.36. Җаваплы башкаручы лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның җитәкчесе яки башка вазыйфаи заты тапшырган аңлатмаларны һәм элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны карарга тиеш.

Тапшырылган аңлатмаларны һәм документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмаган очракта, Министрлык мәҗбүри таләпләрнең бозылу билгеләрен ачыкласа, Министрлыкның вазыйфаи затлары планнан тыш күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы.

Җаваплы башкаручы күчмә тикшерү үткәрүнең таләп ителүе яисә таләп

ителмәве турында карар кабул итә. Күчмә тикшерү үткәрүнең таләп ителүе турында карар кабул итү критерие - лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) документларны карау барышында лицензия таләпләре бозылу билгеләре табылу, алар әлеге Регламентның 5.41 бүлекчәсе нигезендә күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора.

Документларга планнан тыш тикшерү үткәргәндә лицензиягә дәгъва кылучыдан, лицензиаттан алар тарафыннан документларга тикшерү барышында тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматны таләп итү тыела.

Күчмә тикшерү үткәрү турында карарны министр (министр урынбасары) кабул итә.

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, җаваплы башкаручы планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли.

Башкару срогы: аңлатмалар һәм (яки) документлар алынган яисә документларга тикшерү актын рәсмиләштергән вакыттан ике эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тапшырган аңлатмаларның һәм (яки) документларның җаваплы башкаручы тарафыннан каралуы;

кирәк булган очракта, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проекты.

5.37. Документларга тикшерү үткәргәндә Министрлык лицензиягә дәгъва кылучыдан, лицензиаттан документларга тикшерү предметына карамаган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуксыз.

5.38. Җаваплы башкаручы документларга планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Регламентның 5.21, 5.22 пунктларында билгеләнгән тәртиптә документларга планнан тыш тикшерү акты төзи.

5.39. Тикшерү үткәрелгән лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән, яисә ачыкланган таләп бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, Министрлыкка әлеге Регламентның 5.24 пунктында билгеләнгән тәртиптә ризасызлыгын белдерергә хокуклы.

5.40. «Документларга планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасын башкару нәтиҗәсе тиешле тәртиптә электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтына куела, «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 1.1 пункты нигезендә үткәрелә торган планнан тыш тикшерүләрдән башка, шул исәптән лицензия бирү турында гариза тапшырган лицензиягә дәгъва кылучы, лицензияне яңадан рәсмиләштерү, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза тапшырган лицензиатка карата), Татарстан Республикасының чара күрү актларының җыелма реестрына кертелә.

## «ПЛАННАН ТЫШ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.41. «Планнан тыш тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез була.

Күчмә тикшерү документларга тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләрне башкару мөмкин булмаса үткәрелә:

1) Министрлык карамагында булган лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат документларындагы белешмәләрнең тулылыгына һәм дөреслегенә инану;

2) лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат эшчәнлегенең лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен тиешле контроль чараларын үткәрмичә генә бәяләү.

5.42. 99-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 7 һәм 9 өлешләрдә каралган очракларда лицензиягә дәгъва кылучыга яки лицензиатка планнан тыш күчмә тикшерү предметы булып лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашырганда лицензиягә дәгва кылучы яки лицензиат кулланырга җыенган бүлмәләр, биналар, корылмалар, техник чаралар, җиһазлар, башка объектларның торышы, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәткәрләрнең булуы, мондый объектларның һәм хезмәткәрләрнең лицензия таләпләренә туры килүен бәяләү максатларында.

99-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 10 өлешендә каралган планнан тыш күчмә тикшерү предметы булып лицензиат документларында аның эшчәнлеге, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган бүлмәләр, биналар, корылмалар, техник чаралар, җиһазлар, башка объектларның торышы, лицензиат хезмәткәрләренең лицензия таләпләренә туры килүе турында мәгълүматлар, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр, лицензия таләпләрен үтәү, лицензия таләпләрен бозуның ачыкланган очракларын бетерү турында күрсәтмәләрне үтәү буенча лицензиат күргән чаралар тора.

5.43. Күчмә тикшерү (планлысы да, планнан тышы да) лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның лицензияләнә торган эшчәнлек төрен фактик гамәлгә ашыру урыны буенча уздырыла.

5.44. Планнан тыш күчмә тикшерү әлеге Регламентның 5.14 пунктында күрсәтелгән гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.45. Әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек башлыгы, әлеге Регламентның 5.15 пунктына таянып, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгели.

Башкару срогы: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән алып бер эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.46. Җаваплы башкаручы  планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли һәм аны министрга (министр урынбасарына) кул кую өчен җибәрә.

Тикшерү үткәрү турында боерыкның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Башкару срогы: җаваплы башкаручыны билгеләгән көнне яисә киләсе эш көне дәвамында.

Гамәл нәтиҗәсе: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) кул куйган боерык.

5.47. Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән очрак нигез булса, җаваплы башкаручы:

- лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына лицензиатка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза әзерли һәм аңа министрдан (министр урынбасарыннан) кул куйдырта (планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында гаризаның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

- лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза тапшыра яисә аны тапшырылуы хәбәр ителә торган заказлы почта юлламасы белән яки квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә юллый. Бу гаризага планнан тыш күчмә тикшерү өчен нигез булган белешмәләрне үз эченә алган планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсе кушып бирелә.

Алгарышлы социаль-икътисадый территория резидентларына карата планнан тыш тикшерү үткәрүне прокуратура органнары белән килештерү тәртибе 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 8 өлеш һәм Россия Иктисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен гражданнар тормышына, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкарьләргә), Россия Федерациясе Музей фондының музей предметлары һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, илкүләм китапханә фонды составына керүче махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган документларга, дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл булу куркынычы янау, лицензия таләпләре бозылуның ачыклануы нигез булса, мондый бозулар башкарылганда кичектергесез чаралар күрү таләп ителгәнгә күрә, Министрлык, контроль чараларын үткәрү турында прокуратура органнарына гаризаны һәм аңа кушып бирелгән Министрлыкның планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыгы күчермәсен һәм аны үткәрү өчен нигез булган белешмәләрне үз эченә алган документларны егерме дүрт сәгать эчендә прокуратура органнарына юллап, кичекмәстән планнан тыш күчмә тикшерү үткәрә башларга хокуклы. Бу очракта тиешле документлар кергән көндә прокурор яки аның урынбасары планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул итә.

Башкару срогы: лицензиатка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерыкка кул куелган көндә.

Гамәл нәтиҗәсе: прокуратура органына юлланган планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында гариза.

5.48. Вазыйфаи зат лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында (үткәрелү өчен нигезләре әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән башка) ул башланганчы кимендә егерме дүрт сәгать кала мөмкин булган теләсә нинди ысул

белән, шул исәптән квалификацияле көчәйтелгән электрон имза куелган һәм лицензиягә дәгъва кылучының лицензиатның электрон почта адресына, әгәр мондый адрес тиешенчә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса яисә лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан Министрлыкка элек тапшырылган булса, электрон документ җибәреп, хәбәр итә.

Министрлык әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш күчмә тикшерүне лицензиатка алдан хәбәр итмичә генә үткәрергә хокуклы.

Башкару срогы: лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка тикшерү үткәрелә башланганчы кимендә егерме дүрт сәгать кала хәбәр итү зарур.

Гамәл нәтиҗәсе: тикшерү үткәрү турында лицензиатка хәбәр итү (лицензиатка юлланган тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсе).

5.49. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү әлеге Регламентның 5.18 - 5.20 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.50. Тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.21, 5.22 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Яңа ачыкланган таләп бозулар, шулай ук системалы рәвештә таләпләр бозу фактлары мәҗбүри тәртиптә теркәп куела.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органы белән килештереп гамәлгә ашырылган булса, планнан тыш күчмә тикшерү актының күчермәсе тикшерү акты төзелгән көннән алып биш эш көне эчендә прокуратура органына җибәрелә.

5.51. Җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 5.23 пункты нигезендә тикшерүләрне исәпкә алу журналына (ул булган очракта) үткәрелгән планнан тыш күчмә тикшерү турында язма кертә.

5.52. Тикшерү үткәрелгән лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән, яисә ачыкланган таләп бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, Министрлыкка әлеге Регламентның 5.24 пунктында билгеләнгән тәртиптә килешмәвен белдерергә хокуклы.

5.53. Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү лицензиат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең урында булмавы аркасында яисә лицензиат эшчәнлегенең чынбарлыкта гамәлгә ашырылмавына, яисә лицензиат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең тикшерү үткәрелүнең мөмкин булмавына китергән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә башкарылмаса, Министрлыкның вазыйфаи заты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи, анда аны үткәрүнең мөмкин булмавы сәбәпләре күрсәтелә. Бу очракта Министрлык тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзегән көннән алып өч ай эчендә мондый лицензиатларга карата планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында карарны лицензиатка алдан хәбәр итмичә генә кабул итәргә хокуклы.

5.54. «Лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасын башкару нәтиҗәсе тиешле тәртиптә электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтына куела, «Тикшерүләрнең бердәм реестры»

федераль дәүләт мәгълүмат системасына (294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 1.1 пункты нигезендә үткәрелә торган планнан тыш тикшерүләрдән башка, шул исәптән лицензия бирү турында гариза тапшырган лицензиягә дәгъва кылучы, лицензияне яңадан рәсмиләштерү, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза тапшырган лицензиатка карата), Татарстан Республикасының чара күрү актларының җыелма реестрына, тикшерүләрнең исәбен алу журналына кертелә.

## «АЧЫКЛАНГАН ЛИЦЕНЗИЯ ТАЛӘПЛӘРЕН БОЗУНЫ БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.55. Административ процедураны башлау өчен тикшерүләр үткәргәндә лицензиат тарафыннан лицензия таләпләрен бозуны ачыклау нигез булып тора.

5.56. Административ процедура тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрү ярдәмендә гамәлгә ашырыла һәм түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

- ачыкланган лицензия таләпләрен бозуны, шул исәптән лицензия таләпләрен тупас бозуны бетерү турында күрсәтмә бирү;
- ачыкланган таләп бозулар турында белешмәләрне вәкаләтле органнарга җибәрү;
- лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору, яңарту турында карар кабул итү;
- лицензияне гамәлдән чыгару турында арбитраж судка гариза белән мөрәҗәгать итү.

5.57. Тикшерү нәтиҗәләре буенча лицензия таләпләрен бозу, шул исәптән лицензия таләпләрен тупас бозу ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган лицензия таләпләрен бозуны бетерү турында, аларны бетерү срокларын күрсәтеп һәм (яки) тиешле чаралар күрү турында күрсәтмә бирә, ул әлеге Регламентның 5.21 пунктында каралган тәртиптә, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган таләпләрне исәпкә алып рәсмиләштерелә.

Күрсәтмә тикшерү актына кушымта булып тора, тикшерү акты белән бергә рәсмиләштерелә һәм тикшерү төгәлләнгәннән соң тикшерү акты белән бергә лицензиат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тапшырыла (җибәрелә).

Күрсәтмә әлеге Регламентның 1нче кушымтасы нигезендә билгеләнгән формадагы бланкта тутырыла.

Җаваплы башкаручы лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә бирелгән күрсәтмәне вакытында үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылык турында хәбәр итәргә тиеш.

5.58. Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда лицензия таләпләрен тупас бозуларның тулы исемлеге Лицензияләү турында нигезләмәдә (әлеге Регламентның 2.16 пункты) билгеләнә.

5.59. Әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча, ягъни лицензиат тарафыннан лицензия таләпләренең тупас бозылуы турында мәгълүмат кергән очракта, планнан тыш күчмә тикшерү, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән билгеләнгән тәртиптә килештерелгәннән соң, лицензиатка алдан хәбәрнамә җибәрмичә генә үткәрелергә мөмкин.

5.60. Күрсәтмә алган лицензиат, ачыкланган таләп бозуларны бетерү өчен билгеләнгән срокта, Министрлыкка ачыкланган таләп бозуларны бетерү турында мәгълүмат, шулай ук мондый бозуларны бетерү максатларында, күрсәтмәнең һәр пункты буенча, чаралар үткәрүне раслаучы документлар тапшырырга бурычлы.

5.61. Лицензиат ачыкланган таләп бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү актын алу датасыннан башлап унбиш көн эчендә Министрлыкка язма рәвештә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән тулысынча яки аның аерым нигезләмәләре белән килешмәвен белдерергә хокуклы. Шул ук вакытта лицензиат мондый ризасызлыгына әлеге ризасызлыкның нигезләнгән булуын раслый торган документларны яки аларның таныкланган күчермәләрен кушып бирергә яисә аларны килешенгән срокта Министрлыкка тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы куелган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

5.62. Күрсәтмәнең билгеләнгән срокларда үтәлүен тикшерү үкәргән һәм күрсәтмә рәсмиләштергән җаваплы башкаручы контрольдә тота.

5.63. Ачыкланган таләп бозуларны бетерү срогы узгач, яисә лицензиаттан ачыкланган таләп бозуларны бетерү мәгълүмат алгач, җаваплы башкаручы, ачыкланган бозуларны бетерүне бәяләү мөмкинлегеннән чыгып, документларга планнан тыш яки планнан тыш күчмә тикшерүне әзерли һәм үткәрә. Тикшерү әлеге Регламентның «Документларына планнан тыш тикшерү үткәрү» яки «Планнан тыш тикшерү үткәрү» административ процедуралары нигезендә үткәрелә. Күрсәтмәне үтәүне тикшерү нәтиҗәләре әлеге Регламентның 5.21, 5.22 пунктлары нигезендә рәсмиләштерелә.

5.64. Ачыкланган лицензия таләпләрен бозуны бетерү үтәлешен тикшерү предметы булып Министрлык тарафыннан бирелгән шундый күрсәтмәне үтәү генә тора ала.

5.65. Планлы тикшерү барышында алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты тарафыннан Россия Федерациясе законнарын бозу ачыкланган очракта, Министрлыкның вазыйфаи затлары алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына закон бозуны бетерү турында күрсәтмә бирә. Закон бозуларны бетерү турында күрсәтмә күчермәсе планлы тикшерү үткәрү нәтиҗәләре турында акт төзү көненнән алып өч көн дәвамында алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына яки аның вәкиленә кул куйдыртып бирелә яисә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентының яки аның вәкиленең мондый күрсәтмәне алу көне турында дәлилләүче бүтән ысул белән тапшырыла. Әгәр күрсәтелгән ысуллар белән күрсәтмәне алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына яки аның вәкиленә тапшыру мөмкин

булмаса, ул заказлы хат итеп почта аша юллана һәм аны җибәрү көненнән алып алты көн узгач алынган санала.

Министрлык алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына планнан тыш тикшерүне закон бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү көненнән ике ай узганнан соң үткәрә. Закон бозуларны бетерү өчен ике айдан күбрәк вакыт кирәк булган очракта, планнан тыш тикшерү закон бозуларны бетерү турында күрсәтмәдә билгеләнгән срокларда, әмма мондый күрсәтмә бирелү көненнән ким дигәндә алты ай эчендә үткәрелә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты планнан тыш тикшерү үткәргәнче закон бозуларны бетерү турында күрсәтмәне үтәмәгән очракта, вәкаләтле федераль орган гаризасы нигезендә, суд карары буенча, эшчәнлек алып бару турында килешү өзелергә һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты статусы гамәлдән чыгарылырга мөмкин.

5.66. Тикшерү турында, шул исәптән тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат Министрлыкның вәкаләт бирелгән вазыйфаи заты тарафыннан «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына, Татарстан Республикасының чара күрү актларының җыелма реестрына, тикшерүләрнең исәбен алу журналына кертелә.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУНЫ ТИКШЕРЕП ТОРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ РӘВЕШЛӘРЕ

6.1. Министрлык вазыйфаи затлар тарафыннан аларның хезмәт бурычларының үтәлешен тикшереп тора, тикшерүләр үткәргәндә вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт бурычларының тиешенчә үтәлмәү очракларының исәбен алып бара, хезмәт урынында тиешле тикшерүләр үткәрә һәм мондый вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

6.2. Әлеге Регламентның үтәлешен тикшереп торуны министр (министр урынбасары) гамәлгә ашыра.

6.3. Әлеге Регламент нигезендә лицензия контролен башкару буенча гамәлләрнең сроклары, эзлеклелеге үтәлүне, Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны министр урынбасары һәм Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәрләре гамәлгә ашыра.

6.4. Министрлык вазыйфаи затларының вәкаләтләре, шул исәптән әлеге Регламентның нигезләмәләре үтәлешен көндәлек тикшереп тору буенча вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәләре нигезләмәләрендә, хезмәткәрләрнең вазыйфа кулланмаларында билгеләнә.

6.5. Министрлык тарафыннан дәүләт функциясе үтәлешенең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп торуга план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү, тикшерелә торган затларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, мәнфәгатьле затларның Министрлык вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) шикаятьләр белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү керә.

Тикшерүләр Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә. Тикшерүләр нәтиҗәләре акт рәвешендә рәсмиләштерелә, анда дәүләт функциясен башкарганда

кимчелекләрнең булмавы яисә ачыкланган кимчелекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәп куела.

6.6. Дәүләт функциясе үтәлешенең тулылыгын һәм сыйфатын план буенча тикшерүләр агымдагы елга Министрлыкның еллык эш планы нигезендә үткәрелә, күрсәтелгән планга алар Министрлыкның дәүләт функциясен башкару компетенциясенә ия Идарә башлыгы тарафыннан кертелә.

6.7. Дәүләт функциясе үтәлешенең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерүләр Министрлык вазыйфаи затларының дәүләт функциясен башкару барышында кабул ителгән яки башкарылган карарларына яки гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) гражданнарның шикаятьләренә (дәгъваларына) нигезләнеп үткәрелә.

6.8. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча дәүләт функциясен башкарганда Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларның булуы ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла һәм ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрелә.

6.9. Дәүләт функциясенең гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан үтәлешен тикшереп тору берләшмәләр һәм оешмаларның уставлары, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Дәүләт функциясен үтәү буенча Министрлыкка тәкъдим ителгән иҗтимагый контроль нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиеш.

6.10. Министрлыкның дәүләт функциясен башкару өчен җаваплы вазыйфаи затлары алар тарафыннан дәүләт функциясен башкару барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлары һәм гамәлләре (гамәлләр кылмавы) өчен җаваплы була.

Министрлык вазыйфаи затларының җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә аларның вазыйфа кулланмаларында беркетелә.

## 7. МИНИСТРЛЫКНЫҢ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛЛӘР КЫЛМАВЫНА) СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БИРҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, башка мәнфәгатьле затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) дәүләт функциясен башкару барышында Министрлык, аның вазыйфаи затларының юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китергән кабул иткән карарларына яки гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерергә хокуклы.

7.2. Шикаять Министрлыкка кәгазь чыганакта язмача яисә электрон рәвештә бирелә. Шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен, шул исәптән Министрлыкның рәсми сайтын, кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында бирелә ала.

7.3. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

а) Министрлык атамасы яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яисә тиешле затның вазыйфасы ;

б) шикаять бирүче мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), юридик затның атамасы, әгәр җавап электрон документ рәвешендә юлланырга тиеш булса, электрон почта адресы, яки җавап язмача юлланырга тиеш булса, почта адресы;

в) шикаять асылын бәян итү (шикаять бирелә торган гамәлләр (гамәл кылмау), дәүләт функциясен үтәү барышында Министрлык вазыйфаи затының карарлары;

г) шәхси имза һәм дата.

Шикаятькә анда бәян ителгән хәлләрне раслаучы документлар һәм материаллар яисә аларның күчермәләре кушымта итеп бирелә ала.

7.4. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып дәүләт функциясен үтәүдә катнашучы Министрлык вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәлләр кылмавы) һәм дәүләт функциясен үтәү барышында кабул ителгән карарлар тора.

7.5. Министрлыкка яки вазыйфаи затына аларның компетенциясенә ярашлы рәвештә кергән шикаять мәҗбүри каралырга тиеш. Шикаятьне караудан баш тарту яки карауны туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

7.6. Шикаятьтә шикаять юллаган юридик затның атамасы (әгәр мөрәҗәгать итүче юридик зат икән), шәхси эшкуарның фамилиясе, җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән шикаятьтә әзерләнә торган, башкарыла торган яки башкарылган хокукка каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять ул теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә шикаять юллаган гариза бирүчегә кире кайтарыла, анда әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Язма шикаятьтә цензурасыз яисә вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата хурлау сүзләре, янаулар булса, шикаять анда куелган сораулар асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта шикаять юллаган мөрәҗәгать итүчегә хокуктан усал ният белән кулланырга ярамау турында хәбәр ителә.

Язма шикаять текстын укып булмаса, аңа җавап бирелми һәм шикаять дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затына аларның компетенциясенә ярашлы рәвештә алар тарафыннан каралырга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаять теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, әгәр аның фамилиясе, почта адресы укырлык булса, гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Язма шикаять текст шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, аңа җавап бирелми һәм шикаять дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затына аларның компетенциясенә ярашлы рәвештә алар тарафыннан каралырга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаять теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Әгәр шикаятьтә гариза бирүчегә элек җибәрелгән шикаятьләренең асылына бәйле рәвештә берничә тапкыр язма җавап бирелгән булса, һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр һәм шартлар китерелмәсә, әлеге шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр Министрлыкка килгән очракта, министр, Министрлыкның

вазыйфаи заты яки моңа вәкаләтле заты шикаять белән чираттагы мәртәбә мөрәҗәгать итүнең нигезсез булуы һәм мөрәҗәгать итүче белән әлеге мәсьәлә буенча язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Бу карар турында шикаять юллаган мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Министрлыкка яки Министрлыкның вазыйфаи затына җавабы «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 4 өлеше нигезендә урнаштырылган сорау булган язма шикаять килгән очракта, шикаять юллаган мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне теркәгән көннән алып җиде көн дәвамында шикаять куелган сорауның җавабы урнаштырылган Министрлыкның рәсми сайты адресы хәбәр ителә, шул ук вакытта суд карарына бирелгән шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә куелган сорауның асылы буенча җавапны дәүләт серен яки федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълүматны фаш итмичә генә бирү мөмкин булмаса, шикаять юллаган мөрәҗәгать итүчегә, күрсәтелгән мәгълүматларны фаш итәргә ярамаганга күрә, анда куелган сорауның асылы буенча җавап бирүнең мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә куелган сорауларның асылы буенча җавап бирә алмауның сәбәпләр алга таба бетерелсә, гариза бирүче Министрлыкка яки аның вазыйфаи затына кабат шикаять юлларга хокуклы.

7.7. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен Министрлыкка гариза бирүчедән шәхсән үзеннән яки аның вәкаләтле вәкиленнән шикаять керү нигез була.

7.8. Министрлыкка яки Министрлыкның вазыйфаи затлары исеменә кергән шикаять, аларның компетенцияләренә яраклы рәвештә, аны Министрлыкта теркәгән көннән алып 30 календарь көне эчендә карала.

7.9. Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) шикаять министрга, министр урынбасарына юлланырга мөмкин.

Министрлыкның гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланырга мөмкин.

7.10. Лицензиягә дәгъва кылучы яки лицензиат, башка мәнфәгатьле затлар шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алырга хокуклы. Мондый төр мәгълүматны һәм документларны алу өчен лцензиягә дәгъва кылучы яки лицензиат Министрлык адресына кәгазь чыганакта язма рәвештә яисә электрон рәвештә сорату җибәрергә тиеш. Министрлыкның вазыйфаи затлары соратылган мәгълүматларны һәм документларны соратуны теркәгән көннән алып 30 календарь көне дәвамында бирергә бурычлы.

7.11. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

1) гамәлгә ашырылган лицензия контроле барышында кабул ителгән Министрлык, аның вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәлләр кылмавынга) шикаятьне канәгатьләндерү, аерым алганда:

- хезмәт урынында тикшерү барышында аның тарафыннан хезмәт бурычларының тиешенчә үтәлмәве фактлары ачыкланган очракта, вазыйфаи затка (вазыйфаи затларга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрү;

- хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган лицензиягә дәгъва кылучыга яки лицензиатка Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгән көннән алып ун көн эчендә язма рәвештә хәбәр итү;

2) Министрлык, аның вазыйфаи затларының лицензия контролен гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән караларына, гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) шикаятьне, бу хакта лицензиягә дәгъва кылучыга яки лицензиатка язма рәвештә хәбәр итеп, канәгатьләндермичә калдыру.

Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 1нче кушымта

Форма

# Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

## КҮРСӘТМӘ №

ачыкланган бозуларны бетерү турында

Казан ш. «__»___________20__ел

Бирелде

_____________________________________________________________________,
(юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның Ф.И.О.)

Юридик затның урнашу урыны (шәхси эшкуарның яшәү урыны адресы)_________
____________________________________________________________,

Салым түләүченең идентификация номеры (ИНН)______________________________

Дәүләт теркәве турында язуның төп дәүләт теркәү номеры
____________________________________________________________________________
(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшкуар өчен)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 20___ елның _____________, _________ номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Административ реформа мәсьәләләре буенча идарәсенең лицензияләү бүлеге вазыйфаи затлары:

____________________________________________________________________________,
(Ф.И.О. вазыйфа)

территориаль аерымланган объектларына план буенча күчмә тикшерү үткәрде,

__________________________________________________________________________
(юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның Ф.И.О.)

алар түбәндәге адреслар буенча урнашкан: ___________________________________
__________________________________________________.

План буенча тикшерү нәтиҗәләре буенча 20___ елның __________, _________ номерлы акты төзелде, _________________________________ тарафыннан имзаланды.
(юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар Ф.И. О.)

Тикшерү актының икенче нөсхәсе кул куйдыртып бирелде ____________________

_______________________________________________________________________________.
(юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар Ф.И. О.)

План буенча тикшерү үткәрү барышында:___________________________________
___________________________________.
(норматив хокукый ктны күрсәтеп, хокук бозуларның эчтәлеге)

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 1 пункты; «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 пункты нигезендә күрсәтмә бирәм:

1. Лицензия таләпләренең үтәлешен раслап, югарыда күрсәтелгән хокук бозуларны бетерергә: ____________________________________________________
(лицензия таләпләренең исемлеге)

2. Әлеге күрсәтмәне үтәү турында язма рәвештә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына хәбәр итәргә һәм аның үтәлүен раслый торган документларның күчермәләрен 20___ елның «___» ________ кадәр тапшырырга.

Күрсәтмәгә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Әлеге күрсәтмәне билгеләнгән вакытында үтәмәгән өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 ст. 1 өлеше нигезендә җаваплылык каралган.

Күрсәтмәне төзегән вазыйфаи зат

_________________________ _______________________ ________________________
(вазыйфа) (Ф.И.О.) (имза, дата)

Күрсәтмәне алды:

_________________________ _______________________ ________________________
(вазыйфа) (Ф.И.О.) (имза, тапшыру датасы)


_____________________________________________________________________________
(дата һәм юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ номеры)


Күрсәтмә почта аша җибәрелде:

____________________________________________________________
(дата, заказлы хат номеры, хәбәрнамәләр)

Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 2 нче кушымта

# ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕҢ БЛОК-СХЕМАСЫ




Лицензия таләпләре бозылу фактларының булмавын билгеләү
Лицензия таләпләре бозылу фактларын билгеләү
Тикшерү тәгәлләнгән көндә ике нөсхәдә тикшерү актын төзү һәм имзалау
Лицензия таләпләренең ачыкланган бозылуларын бетерү турында күрсәтмә төзү
Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт хакимияте органнарына мәгълүмат юллау
Лицензиягә дәгъва кылучыны, лицензиатны (аларның вәкилләрен), шулай ук лицензия контроле чараларын үткәргәндә булган затларны акт белән (лицензия таләпләренең ачыкланган бозылуларын бетерү турында күрсәтмә) таныштыру
Лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, тикшерү акты белән танышуы турында яисә танышудан баш тартуы турында кул куйдыртып, кушымталар күчермәсе белән тикшерү акты нөсхәсен тапшыру яки тапшырылуы турында хәбәр ителә торган почта элемтәсе юлы белән
Тикшерүләрнең исәбен алып бару журналында, әгәр ул булса, үткәрелгән күчмә тикшерү турында җаваплы башкаручы керткән язма

Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 3 нче кушымта

## ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРГӘНДӘ ВЕДОМСТВОАРА МӘГЪЛҮМАТИ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КЫСАЛАРЫНДА БАШКА ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫННАН, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫННАН ЯИСӘ ОЕШМАЛАРДАН МИНИСТРЛЫК ТАРАФЫННАН СОРАТЫЛГАН АЛАР КАРАМАГЫНДА БУЛГАН ДОКУМЕНТЛАР ҺӘМ (ЯКИ) МӘГЪЛҮМАТ ИСЕМЛЕГЕ

| Соратылган документ атамасы һәм (яки) соратылган мәгълүмат | Карамагында соратылган документлар һәм (яки) мәгълүмат булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешма |
|---|---|
| 1 | 2 |
| лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) милек хокукында яки закон нигезендә башкача рәвештә җир кишәрлекләре, биналары, корылмалары булуын раслаучы документлар | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
| Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
| Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |